www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 27 (1443) 14 июль 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

6

Курган өлкәсендәге коточкыч янгында зыян күргән Эчкен авылы халкы милләттәшләребез ярдәмендә өметләнә.

12

Г.Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театры безне алдагы сезонда «Ал җилкәннәр» спектакле белән сөендерергә җыена.

24

Татар дөньясының гүзәл табигатьле Шәмәрдән авылында кунаклар өчен менә дигән сувенирлар әзерлиләр.

Миллегебез булса, ел буена Җитәр җәйнең шифа-сихәте!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Казанда татар осталарының зәркән эшләнмәләре күргәзмәсе булып узды.
- Актаныштa төбәкара гармунчылар фестивале гөрләп үтте.
- 8 июльдә илебездә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне билгеләнеп үтү уңаеннан Татарстанда да күп чаралар узды.
- Америка Кушма Штатларының бер долларын сатып алу Россиядә йөз сум чигеннән арткан.
- Түбән Новгород каласының «Автозавод» мәдәният һәм ял паркында I Идел буе Сабан туе үткәрелде.
- Түбән Новгород шәһәрендәге элеккеге татар педагогика техникумының диварына, биредә 1920 елларда, күренекле җырчы Рәшит Ваһапов уку турында истәлек тактасы беркетелде.
- Казанның Горький исемендәге үзәк паркында башкорт мәдәниятенә багышланган бәйрәм булды, анда халык башкорт биюен карап, башкорт курае, кубызы һәм җырларын тыңлап рәхәтләнде.
- Арча районының Яңа Кенәр авылында мөселманнар арасында республикакүләм спартакиада үткәрелде, аңа хәтта Мәскәү кебек ерак шәһәрләрдән дә кунаклар килгән иде.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

14 июль - рус шагыйре Гавриил Романович Державинның тууына 280 ел (1743– 1816). Ул Лаеш районы Сокуры авылында туган, 1758–1761 елларда Беренче Казан ирләр гимназиясендә укыган.

– шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Марс Садри улы Шабаевның тууына 90 ел (1933–2008).

– график, карикатурачы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Вячеслав Леонардович Бибишевның тууына 60 ел (1963–2018).

– 30 ел элек Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан Татарстанның Дәүләт гимны кабул ителә (1993). Композитор Рөстәм Яхин музыкасы. Гимн тексты Р.Байтимеровның «Туган ягым» шигыренә нигезләнгән (шагыйрь Г.Рәхимнең әдәби эшкәртүендә); рус теленә Ф.Пираев тәрҗемә иткән.

15 июль – язучы Сөббух Һади улы Рәфыйковның тууына 110 ел (1913–1971).

17 июль – актриса, Татарстанның халык артисты Тәслимә Хәләф кызы Фәйзуллинаның тууына 70 ел (1953–2018).

СЫНАМЫШЛАР

- Болыт килгәндә этәч кычкырса – көн аязырга.
- Төш вакытында салават күпере чыкса, көн бозыла.
- Кура җиләге күп булса, арыш уңа.
- Сорыкортлар безелдәшеп һавада бөтерелсә, аяз көннәр саклана.
- Кич өрәңге яфракларында ябышкак сок чыкса, тиздән яңгыр ява.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 18 минутта** чыкты һәм ул **20 сәгать 22 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 04 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **21 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **21 июльдә 16 сәгать 43 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр (10-17 июль) организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 26 нчы көне

■ **ҖАН АВАЗЫ**

Җәүдәт ГАБДУЛЛИН

Исемнәре җилдә үзгәрүче татар спортчылары

Советлар Союзы чорында татар спортчыларының исем-фамилияләрен русчага әйләндерү һәм «державачыл бөек милләт вәкиле» итеп күрсәтергә тырышу күренеше чәчәк ата.

Татар милләтеннән булган беренче хоккейчы Беляй Бекяшев булып спорт белешмәләренә эләгә, шулай ук Ленинград өлкәсе спортын данга күмгән Әнвәр Хөсәен улы Зверевка да Анатолий Андреевич булып йөрергә туры килә. Зверев Ленинградның «Спартак» футбол клубына Германиядәге Совет гаскәрләре группасы командасында бер ел уйнаганнан соң кабул ителә. 1928 елда Ленинградта туган Бекяшев белән Зверев 1948 елда гына бер үк командада уйнап кала, аннары Бекяшевны Мәскәүгә күчерәләр. Ә 1920 елда Петроградта туган Зверев Карел-Фин союздаш республикасының башкаласы булган Петрозаводск каласына күчә.

Новосибирск каласында туыпүскән хоккейчы Хәмит Исламов урыс милләтеннән булган Люба Степановна атлы кыз белән гаилә кора. Мөгаен, күршеләре белән бер үк командада уйнаган аркадашларының аның исемен тутырып, Хәмит Сираҗетдинович, дип әйтә алмыйча «газап чигүләре» дә үзәгенә үткәндер, безнең хоккейчыбыз берничә айдан туган углына Олег дип исем куштыра. Ни галәмәт, үсеп җитеп, инде үзе дә хоккейчыга әверелгәч, шул Олег Исламов журналистлар каршында үз әтисенең исемен дә юньләп яздыра алмый, ул «Сероздонович»ка әверелә. Урыс сәркатипләренең безнең Габдуллин фамилиясен җанисәптә «Апдулин» йә «Абдулов» дип язып куюлары да күптән «күнегелгән» гадәткә әйләнде бит инде. Менә шул ук ысул белән безнең атаклы хоккейчы һәм тренер Зиннәтулла Билалетдинов та кәгазьләрдә «Зинэтула»га әйләнде, аның әтисе дә «Александр» икән. Безнең атаклы теннис остасы Марат Сафинның әтисенең чын исеме Мөэмин булса, ул эш кәгазьләренә әүвәл «Мобин» булып язылды, аннары инде Михаилга әйләнде.

Без иң беренче итеп телгә алган хоккейчы Билал Бикәчевның Ленинградтагы боз аренасында 4 ел буе партнеры һаман да үзебезнең милләт вәкиле Касыйм Манеев (Миңлегәрәев, Миңлеһадиев – ?) булган. Тик ул Касыймыбыз тора-бара «Казим»га, аның улы Илвар – Ленинградның СКА командасы администраторы – Илья Николаевичка әверелеп куйган. Манеевларның өлкәне үзенең спорт карьерасын Пермь өлкәсендәге Краснокамск каласында тәмамлый-тәмамлавын, әмма ни үкенеч, телевизион тапшыруларда үзен Николай Михайлович дип таныштырудан да тартынмый...

Ташкент каласының «Бинокор» хоккей командасында да берьюлы дүрт «урыслашкан» татар «чәчәк аткан» иде. 1974-1978 елларда «Бинокор»ның капкасын Мәскәү каласыннан килгән Зөфәр (ә афишаларда – Геннадий) Хәсьянов саклады, аның янәшәсендә бер үк бозлавыкта Чиләбе каласында туып-үскән Зиннәтулла (Валерий) Нәдершин, тора-бара, байтак еллар үткәч команданың тренерына әвереләчәк Рамил (Роман) Камалетдинов уйнады. Шушы Рамил Камалетдинов үз иптәшләре белән бергә Үзбәкстанда хоккей спортының үсешенә нигез салды. 1977 елгы сезонда алар янына «Бинокор» командасына Новосибирскида туган Фәһим (Федор) Галәветдинов (Голятдинов) атлы татар килеп кушылды. Ул чорда Ташкент каласында 100 дән артык милләт вәкиле яшәсә дә, ни сәбәпледер, татар-үзбәк-казах исемнәре типкелектә йөрде, барча чиновниклар «өлкән агай» мәнфәгатен генә күккә чөйде.

Шул бер үк хоккей командасы сакчысы Зиннәтулла Нәдершинны гына телгә алсак та, аның атын ничек итеп кенә төрләндереп бетермәделәр бит! «Бинокор»га ул Пермь өлкәсенең Березники каласындагы «Трактор» командасыннан күчеп килгән иде. 1977 елда әүвәл «Бинокор»да, аннары 1978-1979 елларда Ижау каласының «Ижсталь» командасында «Валерий» булып йөрде. Алга таба аны Череповец каласындагы «Металлург»ка күчерделәр, Зиннәтулла исеменә кайтты. Аннары Магнитогорскиның «Магнитка» командасында – Валерий, Харьков каласының «Динамо» командасында «өр-яңадан» Зиннәтулла булып уйнады.

Хәсьянов-Хәсәнҗанов та Ленинградның «Динамо» командасында – Геннадий, Мәскәүнең «Крылья Советов»ында – Зөфәр булып йөргән иде, нинди генә черки яисә кортлар тешләгәндер, «чеп-чи» мөселман дөньясыннан хасил Ташкентта ул тагын Геннадий атын тагып йөрде, ә Ярославльнең «Торпедо» командасына кайткач «өр-яңадан» Зөфәргә әверелде.

Хакыйкать өчен әйтик, «Бинокор» командасы тәмам таркалыр алдыннан «урыслашкан» үзбәк уенчылары белән дә тулган була инде. Үзбәк Хөсәен Кадыйровның исеме – Владимирга, Сабир белән Хәйретдин Галихаҗиевлар Сергей белән Геннадийга әверелә. «Державачыл олуг милләт вәкилләре» арасына үз булып керергә тырышу массакүләм чир төсмерен ала. Киевтә туып-үскән татарыбыз Габдулла Сабиров – Тула өлкәсенең Әекино каласына күчкәч, «Корд» командасында Владимир атлы булып йөри башлый.

Ә хөррият җилләре исеп, баш миләрендәге элекке чирләрне куып тараткач, теннисчы Марат Сафинның Михаил Алексеевичка әйләнгән әтисе кабат ашыга-кабалана Мубин Алямшеевич атына әйләнеп кайта; үзе Киевтә туып, безнең Түбән Камадагы «Нефтехимик» командасында тренер булып эшли башлаган Валерий Голдобин – Валерий Болгарига, «Рубин» командасы башлыгы Вилен Васильевич Илларионов – Әхмәровка әверелеп куя.

Ә Украинаның бүгенге футболы белән әле булса күренекле спортчыларыбызның берсе – Ирек (Игорь) Фәрхәт улы (Федорович) Гатауллин җитәкчелек итә. Ул Казанда туган, аны әти-әнисе бәләкәй чагында Винница каласына алып киткән, украин футбол осталыгына өйрәтү мәктәбендә чыныккан һәм 1975 елда гына «Рубин» командасына әйләнеп кайткан. Аннары ул Үзбәкстанга күченә, Хорезм һәм Яңа Арык калаларының спорт данын яклый. Бүген исә Украинада профессионал футболчылар ассоциациясе президенты, халыкара футбол федерациясендә украинлылар вәкиле.

вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

ЧИТТӘН ТОРЫП СЕРЛӘШҮ

Шанхай хезмәттәшлек оешмасының (ШОС) 4 июльдә Яңа Дәһлидә (Һиндстан, быел оешмада ул рәислек итә) күзгә-күз очрашып узарга тиешле 23 нче саммиты, кайбер сәбәпләр аркасында, видеоэлемтә аша онлайн форматта үткән. Әлбәттә, бу ирекле көннән генә болай эшләнмәгәндер (аңа әле соңрак аерым да тукталырбыз). Шуңа да карамастан, әлеге хәбәрне тараткан «Москва. Кремль. Путин» (Россия-1, ВГТРК) программасында бу хакта: «Но сам факт общения лидеров этих стран привлекает особое внимание всего мира и ревность Запада», – дип билгеләделәр. Ә нинди мөһим мәсьәләләр хәл ителгән соң андый «читтән торып очрашу»да? Хезмәттәшлекне максат иткән бу оешманың хезмәттәшлеге нәрсәдә күренә?

Сәяси күзәтүчеләр әйтүенчә, ШОС илләре (Казахстан, Кыргызстан, Кытай, Пакьстан, Россия, Таҗикстан, Үзбәкстан, Һиндстан) җитәкчеләренең саммитта ясаган чыгышларында гомуми юнәлеш мондыйрак булган: Көнбатышның оешмага бүленеш кертү омтылышына каршы һәм уртак үсеш хакына берләшү. Саммитта кабул ителгән йомгаклау документында исә түбәндәге тезислар да чагылыш тапкан: ШОС эшчәнлеге башка дәүләтләр һәм халыкара оешмаларга каршы юнәлдерелмәгән; халыкара үсеш һәм төбәкләр үсеше проблемаларын хәл иткәндә идеологик, конфронтацион һәм блокларга бүленеп караш белдерүләрне булдырмау; яңа типтагы халыкара мөнәсәбәтләр гаделлек, бер-береңне хөрмәт итү, тигез хокуклылык һәм үзара отышлы хезмәттәшлеккә корылырга тиеш һ.б. Документта ШОС әгъзаларының, төбәктәге һәм халыкара аренадагы реаль хәлләрне бердәй бәяләүгә таянып, киң вәкаләтле, демократик, гадел вә күп үзәкле дөньяви тәртип урнаштыру тарафдары булуларын раславы, Бөтендөнья сәүдә оешмасын икътисади чынбарлыкка туры китереп реформалау кирәклеге, галәм киңлекләре сугыш коралыннан азат булырга тиешлеге, шулай ук 2024 елны «экология елы» дип игълан итәргә килешүләре турында да әйтелә. ШОС берьяклы санкцияләр кертүгә һәм чит дәүләтләрнең эчке эшләренә тыкшынуга да каршы. Бу саммитта Иранны оешмага әгъза итеп алганнар, киләсе елда инде Беларусь та анда әгъза булып керергә җыена икән.

Күрүебезчә, йомгаклау декларациясендә сүз гаделлек, демократия, тигез хокуклылык хөкем сөргән, күп үзәкле дөньяви тәртип урнаштыру, шулай ук идеологик, конфронтацион һәм блокларга бүленеп караш белдерүләрдән арыну турында бара. Ә оешмада әгъза булып торган илләргә игътибар итсәк, аларның күпчелеген, асылда, элеккеге Советлар Берлегенә кергән, шулай ук Пакьстан, Иран кебек тоталитар режимга корылган дәүләтләр тәшкил итә (анда Төньяк Корея гына җитми кебек). Беришләренең тышкы сәясәттәге эш-гамәлләренә һәм Украина тирәсендәге конкрет фактларга да игътибар итсәк, декларациядә әйтелгәннәр инде тәмуг фәрештәсенең тәүбәгә килүен дә хәтерләтә башлый. Нәрсә бу? Әллә соң оешмага кергән илләр, чыннан да, гаделлек, демократия һәм тигез хокуклылык юлына басарга, шул нигездә җиһанда күп үзәкле яңа дөньяви тәртип урнаштырырга җыеналармы? Бирсен Хода! Тик, кызганычка, эшләр башкачарак тора кебек. Хактан да, үз декларациясендә кайсы оешма гына «бөтен дөньяда тоталитар режим урнаштырыйк» дип чакырыр икән? Икенчедән, бу мөмкин дә түгел. Чөнки бүгенге деградация шартларында «глобальләшү»нең андый юлы да кешелек цивилизациясенең юкка чыгуына гына китерер иде. Хикмәт нәрсәдә соң? Көнбатыш белән Глобаль Көньяк арасында уртак тел табылырмы? Нинди соң ул һәр ике тарафны да канәгатьләндерә торган һәм Җирдә яшәешне гармонияле итә торган «яңа дөньяви тәртип»?

Күрәсең, хикмәт монда дөнья тотучыларның ул «тәртип»не, элеккечә үк, геосәяси ысуллар белән урнаштырырга омтылуында. Ә алар эшләми. Икенчедән, андый «тәртип»ләр кыска вакытлы була (Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларыннан соң урнаштырылган «тәртип»ләр моны ачык күрсәтте). Бердәнбер юл – яңа дөньяви тәртипне метасәяси нигездә (илаһият канунннары буенча һәм абсолют кыйммәтләр системасында яшәүгә күчеп) кору. Хәлбуки, бүгенге геосәяси бүленешне (Көнбатыш-Глобаль Көньяк) дөнья тотучы кавем моңа кадәр үткәргән «мәҗбүри глобальләштерү» сәясәтенең дәвамы дип карарга да нигез бар. Моңа кадәр бүленеш «Көнбатыш-Кытай» шәкелендә булса (геосәяси планда Россия – алар арасында буфер зонасы, ә Көнбатыш өчен «сәясәт коралы» һәм «туп азыгы» ролен дә үти), хәзер инде ул «Көнбатыш-Глобаль Көньяк» форматын ала. Көнбатыш өчен геосәяси хәйлә шунда ки, Россия белән ул, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда (яңа дөньяви тәртип урнаштыру) эш итә. Ә ШОС саммитының видеоэлемтә аша онлайн форматта үткәрелүенә килгәндә, моны Халыкара җинаять судының (МУС), Украинадан балаларны законсыз депортацияләүдә гаепләп, В.Путинны кулга алуга биргән ордеры белән бәйләп карарга кирәктер. Димәк, 22-24 августта КАРда БРИКС илләренең саммиты да онлайн форматта узарга мөмкин.

Фоат УРАЗАЙ.

Балаларга кортлар күче ябырылган

Башкортстанда балаларга бал кортлары һөҗүм иткән. Табибләр балаларның тәненнән 465 бал корты угын алган. Бу турыда «Башинформ» яза.

Ишембай районының Әхмәр авылында 26 июньдә абыйлы-энеле 2 малай үзләре генә урман аланына бара. Бирәдә аларга йорт бал кортлары күче һөҗүм итә. Кортлар баланы бик күп тапкыр чага. 8 яшьлек кече малай бал кортларыннан качып китә ала. Ул өйгә кайта һәм абыйсының урманда калуын, үзе кайта алмавын әйтә. Малайларның атасы һәм туган абыйсы урманга бара, алар бал кортларын куып, баланы коткара.

Малайларны авылда медпунктка алып киләләр. Шунда беренче ярдәм күрсәткәч, «ашыгыч ярдәм» белән Стәрлетамак балалар хастаханәсенең реанимация бүлегенә илтәләр.

«Балаларны тәҗрибәле табибләр командасы коткарды. Реанимациядә балаларның аяклары, куллары, битләре, колаклары, чәч араларыннан 465 бал корты угын алдылар», – дигәннәр хастаханәнең матбугат хезмәтендә.

Хәзер малайлар хастаханәдә, хәлләре яхшыра, аларның гомеренә куркыныч янамый. Дәвалау дәвам итә.

«Хәзер бал кортларының балаларга ни сәбәпле ташлануын ачыкларга кирәк.

Гомумән, бал кортларыннан ераграк булырга тырышыгыз. Йорт бал кортлары ник урманда булган – белмим. Бәлки, шунда нектар җыйганнардыр. Ләкин балаларга һөҗүм итү сәбәбе билгесез.

1 нче биттә – Миллек әзерләү күренеше. Фото «Татмедиа» фотоархивыннан алынды.

Каләмдәшләр Мамадыш төбәгендә

Язучылар, журналистлар төпле әйбер иҗат итәм дисә, халык арасында булырга тиеш. Милләтеңне борчыган хәлләрне белү, фикерләрен, уй-хыялларын аңлау лазем. Күренекле драматург Т.Миңнуллин гел гади халыкның аралашуын тыңлап, кызыклы диалогларны дәфтәргә туплый, мәгълүмат җыю өчен берәр төбәктә атналар буе йөреп кайта иде. Ул «Гөргөри кияүләре» комедиясен язу өчен дә Лаеш районының керәшен авылы Ташкирмәндә атналар буе ятты. Нәтиҗәдә, кызыклы да, гыйбрәтле дә әсәр туды. Мишәрләргә багышланган «Йөрәк маем» пьесасы да шулай язылды...

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин белән күрешкәч: «Мамадыш төбәге герой-каһарманнарга бик бай бит, шунда Хәтер көнен дә уздырып кайтсак иде», – дип мөрәҗәгать иткәч, күп гасырлык тарихы булган гүзәл калага бар коллектив белән җыелып бардык. Әүвәл һәр ел саен үзгәрә һәм яңара баручы район үзәге белән танышып чыккан идек, аннары Бөек Ватан сугышында башын салган якташлар истәлегенә куелган һәйкәл янына җыелыштык.

Мамадыш районы аяусыз сугышка 16100 кеше озаткан, шуларның 8 мең чамасы гына әйләнеп кайта алган. Алар арасында Советлар Союзы Герое исеменә Кече Кирмәннән Гафият Нигъмәтуллин, Соколка бистәсеннән Михаил Просвирнин, Албай авылыннан керәшен Михаил Москвин, шул ук авылдан янә Иван Максимов белән Николай Гаврилов, Түбән Ушмы авылыннан Миңлеәхмәт Әүхәдиев лаек булган. Бүгенге көннәрдә Россия Герое исеменә лаек булган Георгий Смирнов та Албай авылыннан.

...Без, иҗат десанты, Мамадыш каласының үзәгендә Мәңгелек ут каршына тезелештек. Хәтер яңартабыз. Барыбызның да туганы, бабасы, атасы яки агасы әлеге дәһшәтле сугыш кырында ятып калган. Митинг бара, район җитәкчесе Анатолий Иванов Бөек Ватан сугышы һәм әфган алышларында катнашкан каһарман солдатларны исемләп телгә ала. Башны түбән иеп, кайтмый калган солдатлар өчен дә, туган туфрагында вафат булган ветераннар рухына багышлап та күңелебездән догалар ирештерәбез. Җыен тәмам булгач, шәһәр музеена кереп, борынгы тарихыбызны янә бер мәртәбә күз алдыннан кичерергә дә онытмадык. Мамадыш атамасының нигып калуын Мәмәт ишан исеме

● «Казан утлары» Иске Җөридә.

белән бәйлиләр. Без бик разый, дин әһеле дога биргән гамәл гел отышлы була. Бүген чәчәк атып утыручы Мамадыш – теләсә кайсы кунакны елмаеп каршыларга әзер, игелекле төбәк.

Мамадыш – безнең каләмдәшләр булган Рәис Даутов, Шаһинур Мостафин, Зиннур Мансуров, Марат Закир, Ринат Мөхәммәдиев, Әхмәт Гадел, Варис Гали, Рафаэль Газизов, Шәйхи Маннур, Әлфәт Закирҗанов, Хуҗи Мәхмүтов, Амур Фәләх һ.б. бик күп әдипләрнең газиз ватаны да. Мамадышны Татарстанның халык артистлары Георгий Ибушев, Миңгол Галиев, Хәлил Мәхмүтов, күренекле рәссам Нәҗип Нәккашны бүләк иткән өчен дә яратабыз.

Район халкы тиздән Җөри авылында янә Питрау Сабан туен үткәрергә әзерләнә. Тирә-юньнең табигате гүзәл, чал Нократ елгасы белән чал Чулман да – республикабызның йөзек кашлары. Мамадышлыларга киләчәктә дә чәчәк атып, гүзәл хезмәт нәтиҗәләре белән сөенешеп яшәргә язсын!

Рәдиф СӘГЪДИ.

ТАТАРСТАНДА КЫР КӨНЕ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Россия авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев «Бөтенроссия кыр көне»н һәм җир сөрү буенча X Россия чемпионатын тантаналы рәвештә ачты. Чаралар «Казан Экспо»да узды.

«Мондый зур чараларның безнең республикада узуы куанычлы. Безнең авыл хезмәтчәннәре Татарстанның потенциалын күрсәтә, тәҗрибә уртаклаша, яңа эшлекле партнерлар таба алачак. Безгә бу мөмкинлекләр бик кадерле», – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов.

Дмитрий Патрушев әйткәнчә, быел беренче мәртәбә «Бөтенроссия кыр көне» күргәзмәсен һәм җир сөрү буенча X Россия чемпионатын зур бер чарага берләштергәннәр. «Мондый чара уздыруда ярдәм иткән кунакчыл Татарстанга зур рәхмәт белдерәм», – диде ул.

Авыл хуҗалыгы министры «Бөтенроссия кыр көне»н Россиянең авыл хуҗалыгы, агросәнәгать комплексы һәм башка катнаш өлкәләрдәге алдынгы казанышларның «витринасы» дип атады.

«Күргәзмәдә үсемлекчелек, терлекчелек, эшкәртү, фән, технология, банк секторы һәм авыл хуҗалыгы машиналары төзелеше тармаклары вәкилләре катнаша. Һөнәри диалогны үстерүгә һәрвакыттагыча эшлекле программа юнәлдерелгән», – диде ул.

Министр сүзләренчә, Җир сөрү буенча чемпионат – тармакның көн кадагында торган тагын бер мөһим вакыйгасы – ул ел саен үзенең чикләрен киңәйтә. Быел, юбилей елында Россиянең 37 субъектыннан, шулай ук Белоруссиядән һәм башка дустанә илләрдән механизаторлар командалары катнашты.

Ачылыш тантанасына хәтле Рөстәм Миңнеханов һәм Дмитрий Патрушев селекция, агрохимия, үсемлекләрне саклау, югары технологияле техника өлкәсе буенча тәкъдим ителгән эшләрне карады. Чарада Татарстанның Дәүләт киңәшчесе М.Шәймиев тә катнашты.

* * *

Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин да «Казан Экспо»да «Бөтенроссия кыр көне – 2023» кысаларында үткән X җир сөрү буенча ачык чемпионатның ябылу тантанасында катнашты. Бу хакта ТР Рәисенең матбугат хезмәте хәбәр итте.

А.Песошин чемпионатның соңгы атнада якты вакыйга булуын билгеләп үтте. «Кырда без илнең иң яхшы механизаторы исеме өчен намуслы һәм матур көрәш күрдек. Ярышлар тәҗрибәле катнашучыларга яңа үрләр яулау булды, ә яңа килүчеләр өчен уңышка трамплин булуына ышанам», – диде ул.

Премьер-министр җиңүчеләрне котлады һәм бүләкләде, шулай ук Татарстанның бу вакыйганы алга таба да уздырырга әзерлеген белдерде.

«Без киләчәктә дә республикабыз кырларында җир эшкәртү буенча чемпионат кабул итәргә әзер. Шуңа күрә саубуллашмыйбыз, ә яңа очрашуларга кадәр дип әйтәбез», – диде ТР Хөкүмәте башлыгы.

Чемпионатта илнең 35 төбәгеннән, шулай ук Беларусь, Казахстан, Кыргызстан һәм Ираннан 65 механизатор катнашты. Иң яхшылары ике дисциплина буенча ачыкланганнар: җир сукалау осталыгы һәм тракторны фигуралы йөртү. Беренче дисциплинада беренче урынны Татарстаннан Ирек Галиев, икенчелекне – Орел өлкәсеннән Виктор Кудинов, өченче урынны Мордовиядән Сергей Митрофанов алды. Трактор-шоуда Саратов өлкәсеннән Сергей Сергейчев җиңде. Икенче урында – Кемерово өлкәсеннән Алексей Филипов, өченчедә – Свердловск өлкәсеннән Андрей Савченко.

Ярышларны оештыручы, «Росагролизинг» генераль директоры Павел Косов республикага рәхмәт белдерде һәм ярышларны үткәрү дәрәҗәсен югары бәяләде.

В.ВАСИЛЬЕВ.
tatar-inform.

Чатыр тауда фольклор фестивале

Азнакайның «визит карточкасы» булган Чатыр тау итәгендә Татарстаннан һәм күрше-тирә республикалардан 50 ләп фольклор коллективы җыелды.

Азнакайның Чатыр тавында халыкара «Чатыр тауда җыен» халык иҗаты фестивале башланды. Фестивальнең зур кунаклары арасында ТР мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов, халык шагыйрьләре Марсель Галиев, Газинур Морат һ.б. бар иде.

«Чатыр тау – Азнакайның иң биек ноктасы – 14 нче мәртәбә төрки халыкларның фольклор коллективларын үз янына җыя. Безнең тау халыкларны берләштерә торган урын», – дип бәйрәмне ачып җибәрде район башлыгы Марсель Шәйдуллин.

ТР мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов быел Татарстанда гореф-гадәтләр елы булуын искәртте. «Чатыр тауда җыен» фестиваленең республиканың мәдәни тормышында зур вакыйга булуын ассызыклады.

Халык шагыйре Марсель Галиев якташларын бүгенге бәйрәм белән котлады. «Чатыр тау итәгендә халык Күк тәңрегә якыная. Монда көчле энергия барлыгын сизәбез», – диде ул. «Марсель Галиев – Чатыр тау турында шигырьләр һәм проза әсәрләре язган әдип. Ул язганчы тау бу дәрәҗәдә билгеле түгел иде әле», – диде Газинур Морат.

Бәйрәмдә Татарстанның Азнакай, Актаныш, Алексеевск, Арча, Әлмәт, Әтнә, Баулы, Балык Бистәсе, Бөгелмә, Зәй, Кукмара, Лениногорск, Мамадыш, Саба, Сарман, Тукай, Чистай, Ютазы, Яңа Чишмә районнарыннан, Чаллы шәһәреннән, Башкортстан Республикасының Бишбүләк, Ярмәкәй районнары, Октябрьский шәһәреннән, Самара өлкәсенең Похвистнево, Шенталы районнарыннан килгән фольклор коллективлары чыгыш ясады.

Бәйрәмдә төрки халыкларның кул эшләре осталарының күргәзмәләре, милли ашлары күргәзмәләре оештырылды.

Шулай ук кунаклар уеннар мәйданчыгында төрки халыкларның милли уеннарында, мастер классларда катнашты. Фестивальдә төрки халыкларның көнкүрешен чагылдырган «Сөлге аланы», «Чәкчәк аланы», «Халыклар дуслыгы урамы», «Сабыйлар аланы», «Уен Fest яшьләр аланы», «Әдәбият аланы» мәйданчыклары бар иде.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Японнарны шаккатырган баянчы

Сәнгать дөньясында тыныч кына, сабыр гына тагын бер йолдыз сүнде. Ул оста баянчы, талантлы музыкант, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин иде.

Авыр хәбәрне ишетү белән йөгереп килдем. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани урамнарында халык бик күп иде. Мәчеттә җеназа укыр алдыннан мулла бабай халыкка: «Нинди кеше иде, бурычлары калмадымы?» – диде. Аны яхшы белүчеләр, бер тавыштан: «Бик яхшы, тыйнак, акыллы, сабыр, матур кеше иде», – дип пышылдады. Әйе, Рәшит шундый кеше иде. Дөньялыкта бөтен эшен төгәлләп, яхшы гамәл, тәртипле, сәнгатькәр балалар калдырып, Балтачка, әнисе янына Соснага кайтып китте...

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен үзара «цех»ларга бүлеп йөртәләр: җырчылар, биючеләр, музыкантлар. Әнә шул музыкантларның җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин – җырчыларга да, биючеләргә дә җан өрүче, тамашачы, халык белән тоташтыручы.

Катлаулы язмыш иясе Рәшит Мостафин гомеренең бер чорында очучы да була – зәңгәр күктә самолетка ут капкач та исән кала алган, СССРның һәм Европаның барлык елгаларын колач салып йөзгән егет. Аннары кулына гармун тотып дөнья иңли.

Менә сәгатьтән артык инде аны көтеп утырам. Ул исә бу юлы да очрашуга вакытында килмәде. Әй, Рәшит, Рәшит, дим, сиңа да 50 тула икән бит инде. Андый чакта синең кебекләр редакцияләрдән китеп тормый, мәкалә яздыра, фотоларын китерә. Синең бәйрәмеңне белми дә калган булыр идек әле, ярый, чакыру китергәнсең, рәхмәт инде. Хәзер бит редакция хезмәткәрләрен андый тантаналарга бик үк чакырып та тормыйлар, ә син чакырасың. Менә шуның өчен дә, юк, аның өчен генә түгел, татар халкының бик кадерле, зурлауга, хөрмәтләүгә лаек музыканты булганың өчен синең хакта күп итеп, матур, җылы итеп язу һич артык түгел.

Моннан берничә ел элек тә очрашуга ул биш минутка соңарып килде, зур гөнаһлы кешедәй, гафу үтенергә тотынды. Аннан соң үзе дә көлеп җибәрде: «Әни өйдә юк иде, – ди. – Концертка, очрашуга барасы булса, миннән уздырып ул әзерләнергә тотына. Янәсе, соңга кала күрмә. Әгәр инде атна арасында ял туры килеп, көне буена өйдә торсаң, әнигә ошамый. Үзенең иң изге саналган сүзләрен мең дә беренче тапкыр кабатларга тотына: «Мин кырык ел буена бер заводта эшләдем, гомеремдә бер генә мәртәбә дә прогул ясаганым булмады, – ди. – Күпсанлы грамоталары, медальләре, рәхмәт язулары бар. Пенсиягә чыкканына егерме елдан артса да, бәйрәм саен заводларыннан котлаулар килеп тора. Сабыр, тыйнак ул минем әни».

Инде үзе ир уртасы булып өлгергән кешенең дулкын-дулкын чәчләре, әгәр кара булса, күптән инде агарыр иде. Ярый әле, арыш көлтәседәй сары булган.

Әни, әни, дип сөйләп утыруы да шундый килешә. Әтисен ул хәтерләми, «кара машина» аны төнлә, улына – бердәнбер баласына – җиде ай булган көнне алып киткән. Шулай да Рәшит аны яхшы хәтерли дә, күргән дә кебек. Әтисе турында әнисе төннәр буе сөйли-сөйли дә елый. Күрәсең, аның турында көндез сөйләргә ярамый. Бик яхшы кеше булган ул һәм бик оста гармунчы. «Син дә шулай булырга тиеш...»

Казан шәһәрендәге Такташ урамыннан шук-шаян усал малаен ялгыз анага гармунчы итү өчен, ай-һай, читен... Ярый әле, Бәдернисаның туган яклары – Балтач районының Сосна, Чапшар авыллары бар. Әнисе улын тыңлата алмаса, шунда китарып куя. Ә бер кайтуда Рәшит шофер Гарәфи абыйга гашыйк булып килә. Өйгә кайткач, аның ничек гармунда уйнавын, ничек машина йөртүен, күргәннәрен сөйләп туя алмый.

Музыка мәктәбенә килгәч, аларны Миңҗамал Мазунова каршы ала. Рәшит өчен бер дә тырышлыгын жәлләми. Малайның күңелендә, җанында күренмәгән моң бар. Ул шуны күреп ала. Әнисен дә соңгы акчасына яшел гармун сатып алырга күндерә. Ә беркөнне Бәдерниса апа матур тавышлы гармунның идәндә таралып ятканын күреп, егылып китә яза. Улы исә, гармун ясыйм, ди. Әни бул да, шул чакта ачуланмый, тавышыңны күтәрми түзеп кара әле. Бәдерниса агыннан, карасыннан бер сүз дәшми.

Бер атнадан Рәшит гармунын күтәреп, эштән кайткан әнисен каршы алырга чыга.

– Ишетәсеңме, тавышы ничек матурланды, – ди.

Музыка мәктәбендә аны мактап, күршеләр тыңлап туя алмый. Ә менә музыка училищесында бер ел укыгач, Рәшит Мостафинны куып чыгаралар. Имеш, музыка аның кебекләр өчен түгел. Канатлар каерыла. Андый чакта малайларга эти кирәк. Аны әни алыштыра. Бара Бәдерниса апа, күз яшьләрен эчкә йотып, урамда узганда сәлам дә бирмәслек кешеләргә тезләнә. Сүзе үтми. Кыңгыр эш кырык елдан соң фаш була: ул елларда училищеда Герасимов классына татар малайларын алмаганнар икән. Рәшит тә ялгыш кына эләккән булган.

Бу – Һади Такташ урамының, Кабан күле буйларының иң бәхетле еллары. Вахитов клубы, күл буйлары җыр-биюдән гөрләп тора. Бергә бокс «сугышына» киләләр, бергә көрәшкә йөриләр, бергәләшеп концертлар куялар. Яшьтәшләренең күбесе очучы, хәрби кеше булып китә. Сигезе профессиональ сәнгатькә аяк баса, халыкка хезмәт итә.

Бәдерниса апа Рәшитне җитәкләп Ижауга китә. Малаен уйнатып карыйлар да, өйрәнергә кыйммәтле баяның булса, алабыз, диләр.

– Бар, – ди Бәдерниса апа, күзләрен дә йоммыйча. Кеше ялганлаганын да кичерә алмаган әнисенә карап, Рәшит авызын ябарга онытып тора. Әнисе исә аның саең: «Бар, бар, аның 800 сумлык ап-ак зур баяны бар», – ди. Үзе исә өйгә кайткач, көне буена туганнарны, дус-ишләрне, сер сыяр кешеләрне йөреп чыга, бурычка акча җыя. Улы хыялланырга да курыккан баянны сатып алып бирә дә укырга озатып кала.

– Менә шуннан соң укымыйча кара инде, – ди Рәшит. – Шундый ул минем әни!

Укучым Рәшитнең баянчы, вак гармуннарда уйнаучы, аларны үзе дә төзәтүче, ясаучы Мостафин булуын аңлагандыр инде. Аны халкыбыз белә, ярата, телевизорлардан сокланып тыңлый. Концертына теләп йөри. Илебезнең Воронеж, Мәскәү, Ленинград кебек шәһәрләрендә Бөтенроссия дипломанты булуын да яхшы хәтерли.

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен Япония алкышлады. Тамашачылар Р.Мостафинның гармуннарын күргәч, исләре киткән. Токионың аккордеончылар ассоциациясе аны кунакка чакырган, туйганчы уйнатканнар һәм бик матур, зур, кыйммәтле, ялт-йолт итеп торган аккордеон бүләк иткәннәр. Дөрес, Рәшит тә бурычлы булып калмаган. Иң кечкенә, иң матур тавышлы гармунын ул аларга калдырган.

Кечкенә гармун, дигәннән, Рәшитнең Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләп йөргән чагы була. Авыр сулап, нишләргә белмичә өйгә кайтып керә.

– Әни, – ди ул, өзгәләнеп, – бир әле бер киңәш. Нишлим, кайдан алыйм икән, бик күп акча кирәк миңа, – ди.

– Мотоциклыңны сат, – ди Бәдерниса апа, бер дә уйлап тормыйча.

Туйганчы йөрергә дә өлгермәгән мотоциклны Рәшит көне-сәгате белән сата да кесә тулы акча ясый. Ә кич белән мәрхүм Фәйзи ага Биккинины сигез гармуны – татар сәнгатенең үткәне һәм киләчәге – Рәшит Мостафиннар өенә күчә. Һәм бүген дә халыкка хезмәт итә. Югыйсә, алар күп акчалы берәүнең затлы шкафына күчеп утырырга да бик мөмкин иде.

– Онытылып, әллә кайларда аунап, әрәм булып яткан уен коралларыбыз бар. Гөслә, ятаган – инде исемнәре дә онытылып бара торган бик матур уен коралларыбыз. Шуларны табасы, халыкка җиткерәсе, таратасы килә. Ләкин еш кына мондый теләкләр каршылыкка очрый.

Һәм шуның өчен дә Рәшит бик еш кына мәсьәләнең хәл ителешен бәйле булган кешеләр белән бәхәскә дә керә. Үз фикерен күзгә бәреп әйтә. Шуның өчен аны хәтта Япониягә дә җибәрмәскә тырышалар. Аннан килгән концертны кабул итүче, караучыларга Рәшитне күрсәтәләр дә башкаларны җибәрергә булалар. Япониягә ат урынына үсә алмый торган тай бирмәкче булалар. Мондый икейөзлелек Рәшитнең башына суккандай була. Ансамбль тетрәнеп кала. Рәшит Мостафин җитәкчелек иткән татар халык уен кораллары оркестры нишләргә белми. Канаты киселгән акчарлак оча аламыни? Ә менә Лима Кустабаева ничек итсә итә, Рәшитне калдырттырмый. Чөнки Италиядә Рәшитсез күргән кыенлыкларны коллектив җитәкчесе әле дә бик яхшы хәтерли. Рәшит үзе бу турыда: «Җыр һәм бию ансамблендә эшләгән Лима Кустабаева – тугызынчы җитәкче», – ди. Һәм Лима Галиевна турында: «Иң оста, иң булдыклы, иң уңай җитәкче», – ди.

Әйе, ул – талантлы музыкантларның бөеклеген җаны-тәне белән аңлый торган җитәкче.

– Әгәр шундый хатын-кызлар – беренче чиратта, тудырган, үстергән, егылганда, тайпылганда, дуслар хыянәт иткәндә терәк булырлык әни, кабындырган, гашыйк иткән, сагышларга салган Һади Такташ урамы кызы, кулдан тотып нота өйрәткән Миңҗамал апалар, иҗатка рух өстәп торучы Лималар... Искәндәрем, әнисеннән дә уздырыбрак биючелеккә укучы кызым Ләйсәнем булмаса, бу тормыш бик күңелсез узар иде. Сабыр, тыйнак, нәфис хатын-кызлар һәрвакыт кирәк, – ди иде Рәшит.

Моннан соң да әле Рәшит Мостафин турында күп яздым. Яратып, сокланып яздым. Нәкъ менә ул, аның кебекләр халкыбызның йөзек кашы, намус сафлыгы, йөз аклыгы булган Татар халык җыр һәм бию ансамблен саклап калды. Соңгы елларда Рәшитнең кызы – биюче Ләйсәннең ире Айрат Хәмитовның ансамбльгә җитәкче булуы да отышлы булды. Бер кинода композиторы Искәндәр Мостафин, дигәч тә сөендем әле. Улмы икән, юкмы икән, никтер ул миңа Рәшитнең улыдыр кебек тоелды. Аның да җырга-моңга гашыйк икәнен белә идем. Рәшит оныкларына, яшь хатынынан туган балаларына татар моңнарын өйрәтте.

Үзе Мәккәгә барып кайтты, хаҗи булды. Урамда, берәр концерт-мазарда очрашсаң, сөйләшеп сүз бетми.

Фәния ХУҖАХМӘТ.

Самара хәбәрләре

Самара өлкәсендә чыгып килүче бердәнбер «Бердәмлек» татар газетасы чыга башлауга быел 33 ел тулды. «Бердәмлек»нең финанс проблемалары да, штаты кыскаруын да укучылары яхшы белә. Шулай да газета атна саен чыгып торуын дәвам итә. Беренче яртыеллыкта укучылары саны кимемәде, хәтта бераз артты да. Икенче яртыеллыкта да хәл начар якка үзгәрмәде.

Укучылары арасында үзләренә генә түгел, «Бердәмлек»не бүләккә яздыручылар да бар. Мәсәлән, өлкә «Туган тел» оешмасы президенты Ильяс әфәнде Шәкүров ел саен өлкә авыллары мәктәпләренә, социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренә, барлыгы 40-45ләп адрес буенча язылу рәсмиләштерә. Бу абунәчеләр өчен дә, газета өчен дә бик зур бүләк. Шулай ук газетага даими рәвештә финанс ярдәм күрсәтүче әби-бабайлар да бар. Отрадный шәһәреннән Роберт Гәрәев килгән саен 1000-2000 сум сәдакасын биреп китә. Шушы көннәрдә генә тугры укучы, «Бердәмлек»нең чын дусты Минтаһир ага Байбеков 5000 сум сәдака китереп тапшырды.

Редакция озак еллар буе «Бердәмлек»кә тугры булып калган укучыларга, татар газетасының гомере озын булсын дип яшәүче милләттәшләребезгә чын күңелдән рәхмәт белдерә.

* * *

«Самара татарлары» журналының быел икенче саны дөнья күрде. Анда Ураза бәйрәме, «Мирас» фестивале турында кызыклы язмалар урын алган. Элекке саннары кебек үк, монысында да телне, моңны саклау турында язила, гореф-гадәтләребезне саклау кирәклеге искәртелә. «Ни кызганыч, милләтне саклау мәсьәләсе көннән-көн кискенләшә бара. Оныкларыбызның киләчәктә үз ана телебездә сөйләшүе үзебездән тора. Безнең журнал геройлары – күп балалы әтиәниләр, танылган җәмәгать эшлеклеләре, авыл хезмәтчәннәре, талантлы яшьләр белән танышыгыз да милләтнең якты киләчәге өчен сез дә алар кебек тырышыгыз. Бергә булыйк, бердәм булыйк!» – дип мөрәҗәгать итә укучыларына журнал редакциясе.

Эчкеннәргә ярдәм санаулы

Янгын нәтиҗәсендә йортсыз-җирсез калган Эчкен – Йолдыз авылының йөзләгән кешесе һаман ярдәм көтә. Дәүләттән бирелгән 500 меңгә йорт салып чыгу мөмкин хәл түгел.

Май башында Себердә чыккан янгыннар нәтиҗәсендә тулы бер татар авылы ут эчендә калды. Эчкен–Йолдыз авылында 380 йортның 228 янып бетте, 7 кеше һәлак булды. «Эчкен халкына бөтен татар дөньясы ярдәм итәчәк!» – диде Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев Сабантуйларның берсендә. Тик ни кызганыч, 2 айга якын вакыт үтсә дә, авылда салынып килүче йортлар саны бик сирәк булуын хәбәр иттеләр.

Төп мәсьәлә – йорт салып чыгарлык акча булмау. Васил Шәйхразыевның Эчкенгә июнь башында булган эшлекле сәфәрендә авылның координацион советы төгәл саннар белән сөйләде. Төзелеш министрлыгы стандартларына туры килгән 110 хуҗалыкка 1 квадрат метр өчен 57 мең бирелә торган сертификат тапшырылган. 35 хуҗалык стандартлар буенча 500 мең күләмендә акча алган. 37 хуҗалыкка акчалата ярдәм бирүдән баш тартканнар, дип хәбәр ителгән иде ул чакта. Тагын күпмесенендер язмышы ул вакытка әле билгеле булмаган, дип аңларга кирәктер. Халык сүзләренчә, 500 мең генә алучылар бик күп.

110 хуҗалык дәүләт подряд оешмалары белән эшне башлап җибәрсә, 500 мең, яки бөтенләй берниндиярдәм дә ала алмаган кешеләргә төбәкләрдәге хәйриячеләр, «Татнефть», Татарстан үзара бүленеп, йортлар салырга килеште. Июнь башында без бурасы күтәрелгән мунча, сарай, гаражлар күрдек. Анысын халык үз көче белән булдырган. Ә йортлар салуда күпләр ярдәм итәчәкләрен белдерде. «Эчкен халкына бөтен татар дөньясы ярдәм итәчәк!» чөнки.

Июнь башында булган сәфәрдә Әнисә апа Мәүлетованың, җитәкчеләрнең күзләренә карап: «Безгә ярдәм итегез, зинһар!» – дип тилмереп-ялварып соравы хәтердә. «Ярдәм итәбез!» – дип вәгъдә бирүләрен Әнисә апа үзе дә онытмый торгандыр.

Әнисә апа белән Наил Мәүлетовларның Эчкендә ныклап яши башлауларының дүртенче елы киткән. Икесе дә пенсиягә чыгып, авылга кайтып төпләнгән. Оныклар белән иркәләнеп, бакча-утар тирәсендә рәхәтләнеп яшәп яткан вакытта бернәрсәсез калалар. Янгыннан бары капкалары һәм балалар мәйданчыгы гына сакланып калган. Әлеге капка дигәне дә – кызыклы капка: үзе тимердән булса да, алгы ягы агач белән бизәлеп эшләнгән. «Капка калды, өй янды», – дип сөйләгән иде Наил абый.

Менә Әнисә апа ихатада төшкән фотоларны җыеп ясалган папкасын күрсәтә: «Менә монысы – безнең йорт, менә монысы минем гаиләм». Зур агач өстәл артында балалары, кияүләре, оныклары белән утыра. Ул агач өстәлне дә, гомумән, өйдәге күп кенә җиһазны Наил абый үз куллары белән эшләгән булган. «Өйдәге бөтен әйберне дә үзем эшләдем. Махсус бук агачыннан тәхет кебек урындыклар да бар иде. «Әнисә миңа балалар белән бергә җыелып утырырга зур өстәл кирәк, дигәч, кухняга 2 метрлы зур өстәл ясадым. Эх, бер нәмә дә калмады», – ди Наил абый.

«Эшләй, әле тагын эшләй. Иң мөһиме, баш өстендә түбә булсын», – дип сүзгә кушыла Әнисә ханым.

– Өй саласыбыз килә. Пенсиягә чыккач, гел шушында яши башлаган идек. Бөтен акчаны шушы өйгә керттек. Балалар мәйданчыгы да ясадык. Шундый матур иде өебез! Башка елларны казлар тота идек. Быел каз алырга өлгермәдек. Илле бройлер алган идек, бөтенесе дә янып бетте. Баш астында түбәбез булса, калганын үзебез тырышабыз. Безгә ярдәм итегез, зинһар!» – дип үтенде Әнисә апа.

Өйләре чыннан да бик матур булган. 2020 елда Беренче май урамындагы Наил һәм Әнисә Мәүлетовлар яшәгән бу йорт авылдагы үрнәк хуҗалык дип табылган һәм йортка шушы хакта язылган элмә такта да куелган булган. Хәзер алар авылдагы буш йортта акча түләп, яллап тора.

Көлгә әйләнгән йортын Наил абый үзе торгызырга тырыша. Кызганыч, Екатеринбургта теркәлүе аркасында аларга дәүләттән сертификат бирмәгәннәр, бары тик 500 мең күләмендә генә ярдәм эләккән. Мәүлетовларның балалары Екатеринбургта яши. Наил абыйның пропискасы да авылда вакытлыча булган.

– Шәһәрдән хастаханә өчен генә теркәлүдән төшмәгән идем. Йөрәккә ачык формада 2 тапкыр операция ясадылар. Якын-тирәдә табибләр дә юк. Ә шәһәрдә мине профессор карый. Шул йөрәк өчен генә пропискам бар иде, – ди Наил абый.

«Башка яшәү урыны бар» дигән сәбәп белән, Мәүлетовларга дәүләт ярдәме тимәгән. Төбәкләр ярдәменең дә ул үзләренә эләкмәвен әйтте.

– Сезнең теркәлү урыныгыз шәһәрдә, торыр җирегез бар, шуңа сезгә юк, – диләр. Мин тагын пропискасы булган 2 кешене беләм. Аларга бушка йорт салып яталар. Гаделлек юк дөньяда. Безгә башка беркем дә ярдәм бирми. «Закон буенча» дияләр дә куялар, каян уйлап чыгарганнар ул законны. 500 мең генә бирделәр, ә 500 меңгә беркем дә йорт салырга теләми. Кая куйыйм мин аны? Истәлеккә туалетка элеп куярмын инде... Татарстаннан килеп, капкаларны видеога төшерделәр, мактый-мактый, телевизордан күрсәттеләр. Булышырга гына теләмиләр. Берәр миллион, яки берәр материал булса да бирсәләр иде. «Әйдәгез, фундамент салып бирегез, йә профнастил, такта булса да бирегез», – дидем. «Юк, йорт өчен шул 500 мең», – диделәр. «Әйдәгез, мин сезгә ул 500 меңне бирәм, сез миңа йорт салып бирәсез», – дим. Кулларын читкә җибәреп карап тора. «Ничек 500 меңгә салыйк?» – ди. «Ә мин ничек салырга тиеш соң?» – дим. «Без гаепле түгел, закон шундый», – диләр. Шуның белән сөйләшү дә бетә. Күпме застройщиклар килде инде монда. Алар безнең белән сөйләшми дә, – ди аптыраган Наил абый.

Авылда төзелеш авыр темплар белән булса да башланып киткән. «Башка кешеләргә салалар. Минем каршыдагы күршедә 2 бетон болгаткыч тора, фундамент салалар. Аларга Татарстан сала, диләр, дөресме-юкмы, белмим», – ди Наил абый.

Шулай да ул кул кушырып утыра торган кешеләрдән түгел. Бригада туплап, йорт төзү эшләрен башларга уйлаган.

– Мин бригада яллыдым. Кая барыйм, үзем салам. Балалар да «булышырбыз» диделәр. Нәмә әйтәек инде... Башка булышырдай кешебез юк, миллионнарыбыз да юк.

«Авырлык белән генә йортлар салуга керештеләр», – диде авылның имам-хатыйбы, Бөтендөнья татар конгрессының Курган өлкәсе бүлеге рәисе урынбасары, авылның координацион совет вәкиле Әхмәдулла Хәбибуллин.

– Кемгә йорт салып бирергә кирәклеген авылның координацион советы хәл итә. Алар эшмәкәрләргә тәкъдим итә, эшмәкәрләр үзләре кемгә саласылары килә, шуларга салып бирә икән. Башкортстаннан килгән эшмәкәр бер пенсионерга йорт сала. Аның түбәсен каплап, күчәләр дә инде. Шыгырданнан Мансур хәзрәт күп балалы гаиләгә салдыра. Ул гаиләдә әниләре укытучы, әтиләре янгын сүндерүче булып эшли. Аларга да 500 мең генә эләккән. Йортның фундаменты әзер инде, хәзер бригада көтәбез. Самара мөфтиятеннән дә фундамент салдырдылар. Нижневартовскидан, Башкортстаннан да бригадалар килә. Дәүләт ярдәме белән булган подрядчиклар да селкенә башлады, фундамент салуга керештеләр. «Татнефть» тә салырга тиеш, алар әле тотынмады, – дип аңлатты авылдагы хәлне Әхмәдулла хәзрәт.

«Бөтен кешегә дә ярдәм эләгәчәкме соң? Бөтенесенә дә ярдәм итеп бетереп буламы?» – дим.

– Беребез дә өйсез калмабыз. Кемнәрнең акчалары җитми, без аларны исемлеккә керттек. Аракы эчештереп, йорт-җирләрен карамаучыларга да үзебезнең авылдагы, күрше татар авылларыннан буш торган 200-300 меңлек өйләр карыйбыз. Алар да урамда калмасын, – диде ул.

Көчле янгыннан зур зыян күргән Эчкен–Йолдыз авылында 12 июльдә Милли шура утырышы һәм авылда никах мәҗлесе булды. Васил Шәйхразыев элек үк «12 июльдә авылда сафка баскан 20-30 йорт булырга тиеш» дип вәгъдә иткән иде. Читтән ярдәм итү болай барса, өметләр акланырмы әле?..

Энҗе ГАБДУЛЛИНА.
intertat.tatar.
Автор фотолары.

Марс ШАБАЕВ

Йөрәгемә иртә кергән идең, Соңлап урын таптың җырымда...

(Танылган шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Марс Шабаевның тууына 90 ел)

Сөю...
Сөелү...
Акыл эшемени?
Ә сөймәгән кеше
Кешемени?!

Шигыремне бүлеп,
Фәрештәдәй,
Син керәсең... –
Өнеммени,
Әллә төшеммени?

Шигъри күктән
Җиргә төшер мине!
Күкрәгеңә капланыйм да синең,
Бөтен дөньясыннан яшер мине...

Мин тоярмын шунда сөю хисен,
Миңа бәхет –
Тою синең исең...

Икәү генә белгән ләззәтләрне
Татыйк әле тизрәк, татыйк әле.

Күңел – комсыз,
Йөрәк көнчел булды:
Яшереп килдем кеше күзеннән.
Аз идеме гыйшкын җырлаучылар,
Җырлап бетермичә өзелгән?!

Җырга исереп күпләр онытылды.
Ә син идең һаман моң гына.
Шауламадың,
Урын дауламадың,
Үз урыныңны белдең тын гына.

Син һәрвакыт янда,
Янәшәдә,
Әйтерсең лә минем күләгәм.
Сиздермәдең...
Ләкин ул җырлардан
Йөрәгең көнләгәндер, көнләгән!

Кил әле, кил!
Йомшак башмаклардан,
Кухня исе сеңгән халаттан
Булсаң ни соң?

* * *
Кабырчыклар җыям, кабырчыклар –
Диңгезләрдән түгел, инештән.
Бала чаклар – энҗе табар чаклар...
Ни кылансаң, бар да килешкән.

– Агымсуда энҗе буламыни?
Ул диңгездә үсә, тирәндә.
Дулкын шавы, дулкын бөллүрендә... –
Зурлар миңа шулай дигәннәр.

Имеш, аны индус егетләре
Гомергә бер генә табалар.
Имеш, аңа җирдә шуңа күрә
Бәяләрне зурдан тагалар...

Күпне таптым, күпне югалттым мин
Агымсудай еллар эчендә.
Хыялдагы җем-җем энҗе хәзер
Чагыла инде, чагыла чәчемдә.

Тик барыбер кабырчыклар җыям,
Диңгезләрдән түгел, инештән.
Хыялдагы бөртек энҗе өчен
Баш тартам мең алтын-көмештән.

Минем энҗем – урман күлләрендә,
Үзебезнең агымсуларда.
Җитми аңа дөнья бәяләре,
Эзлим һаман, эзлим шуңарга.

* * *
Кояш әле агач башларында
Эленеп тора арып, йокымсырап.
Ә түбәндә инде абагалар
Ялваралар төн карасын сорап.

Агачларның бер дә гамьнәре юк,
Алар горур,
Алар мәһабәт.
Изрәткәндер, ахры, җылы нурга,
Яктылыкка булган мәхәббәт.

Якты дөнья!
Яктыны сөйсә дә,
Агач түгел ләса бу бәндәң.
Төшереп тор искә хакыйкатьне:
– Караңгылык үрли түбәннән!

БОДЛЕР РУХЫНДА

Йөрәк сыкравыннан бик талкынган,
Төксе, усал, хәлсез бер мәлдә –
Ярат мине, яме!
Ярат мине!
Юк, бәхет үк сиңа бирмәм дә...
Син бирерсең миңа көзнең шушы
Сүнеп барган шыксыз көнендә
Тик бер назлы мизгел,
Татлы мизгел,
Һәм ул калыр минем күңелдә
Мәңге... мәңге...

Шыксыз көзнең соңгы,
Ләкин тере,
Җәйне хәтерләткән нуры бул.
Син белмисең генә:
Нинди рәхәт
Синең тезләреңә орыну...
Кайнар күкрәгеңә башны куйыйм,
Ойыйм әле шунда,
Ойыйм... ойыйм...
Кайгы-сагышымны тарат, димим, –
Ярат кына, яме!

ХАТКА ЯЗМАС БЕР СҮЗ

«Хат язмыйсың, – дисең. –
Хатка саран!»

Бер язармын әле,
Язармын.
Мәңге бетмәс озын хатымның син
Табалмассың очын-азагын.

Син укыган юлларында булмас
Каным сине көткән минутлар.
Булмас анда син урлаган җәем...
Көзгә кергәч,
Яктым мин утлар.

Шул утларга салдым
(Суга түгел!)
Синең күзләреңнең елтырын...

«Диңгез кибеп,
Таулар җимерелсә...» – дип,
Син укыган идең бер ырым
Шул җәеңдә.

Ырым очты утка!

Таулар исән,
Диңгез кипмәде...

Ләкин мине синең кебек усал
Беркем
Берчак ташлап китмәде.
Ә син киттең кара күңелең белән,
Йөрәк хәзер җансыз чүл төсле.

Мин сусадым сиңа хат язарга,
Каләмемә язар сүз төште,
Бары бер сүз!
Язмыйм –
Сүз көчле!
Мин кызганам сине!

МӘХӘББӘТНЕҢ СЕРЛЕ ТАБИГАТЕ

Мәхәббәтнең табигате нинди?
Бармы чиге сөелү-сөюнең?
Нәрсә соң ул җан-тән яратуы? –
Җавап биреп кара син үзең!

Бер очраклы күз карашы белән
Меңнәр арасыннан тик берне
Сайлап алып,
Үз һәм якын итү
Ник һәрвакыт бәхет китерми?

Менә шул бит үзе, үзе инде
Мәхәббәтнең серле табигате...

* * *
Бакча буйлап торна торык кызлар
Пырхылдашып йөгереп үткәндә,
Кинәт кенә моңсу тавыш телде
Тирә-юньне зәңгәр күкләрдән:
– Тор-рыйк... Тор-рыйк...
Кызлар, тынып калып,
Күзәттеләр торна кәрванын.
Әйтерсең лә якты хыяллары
Торналардай очып барганын,
Үзләренең җирдә калганын
Сизенде дә сизгер күңелләре,
Күрсенделәр кызлар тын гына...
– Тор-рыйк... Тор-рыйк... –
Торна тавышлары
Эреп тынды...
Калды моң гына...
Ә бакчада чыпчык чыркылдаша!
Чыпчык китми,
Чыпчык гел янда.
Янда булгач – бер дә кадере юк:
Нәрсә җитми икән бу җанга?
– Тор-рыйк... Тор-рыйк... –
Моңсу ул тавышлар
Ник күңелне тырнап торалар?
Юксындыра, ымсындыра нигә
Һавадагы ерак торналар?..

* * *
Розага

Үпкәләмә.
Кыз чакларың түгел.
Сүреләдер матурлыгың да...
Йөрәгемә иртә кергән идең,
Соңлап урын таптың җырымда.
Булды вакыт:

Сыеша алмый, ташып,
Кага идең кайнар күкрәгем.
Чайпалдырмадым да,
Түкмәдем дә –
Барыбер сине җырга кертмәдем.

Сине җырлыйм әле,
Тарсынмыйча гына халыктан.

Җырлыйм әле...
Сине һәрчак янда,
Янәшәмдә кебек хис итеп:
Казаннардан килеп җитмәссеңме,
Соңлап туган җырым ишетеп...

* * *
А татарчонку хочется напиться...
Дм. Кедрин

Шагыйрь теленә кергәнсең икән,
И татар гынам, татар баласы!
Хәмерләр эзләп йөргергә кая –
Бер сынык юллап читкә баргансың.
Чәчелгәнсез дә дөнья буйлатып,
Милләтнең эшчән ир-егетләре,
Чәчрәгән сезгә иске тормышның
Шәрабы түгел, гел күбекләре.
Шундый булган ул синең сәрхушлек,
Дөнья ачысы сине исерткән.
Куган чактамы берәр ишектән,
Аһ-зарларыңны шагыйрь ишеткән.
Бәлки, син аңа, телең сындырып:
«Куалар... вот как...» – дигәнсеңдер дә,
Ул «водка» диеп аңлап калгандыр...
Юк, үпкәләмим аңа мин бер дә.
Төрле тел түгел, бер үк телдә дә
Кеше бер-берсен аңламаганда,
Казак камчысы, җандарм итеге
Кан-яшь эчерткән каһәр заманда,
Йөргәнсең читтә, кагылып-сугылып,
Тик бетмәгәнсең сынып-сыгылып...
Синең мескенлек, синең сәрхушлек
Тарих базына калды егылып.
И татар гынам, татар баласы,
Чәчелгәнсең лә син туган җирдән...
Тел очындагын әйтмәгән шагыйрь:
Хөрлек хәмерен эчәсең килгән.

Гомәр Мөхәммәт улы XIX йөзнең беренче яртысында актив иҗат иткән, Оренбургта һәм аның янәшәсендәге Каргалы авылында яшәгән шагыйрь. Аның исемен һәм архивларда сакланган иҗатын әлегә сирәк галимнәр генә белә. СССР чорында аның иҗатын барлаучы фән докторы мәрхүм Мәсгуд Гайнетдинов булды (кара: Татар әдәбияты тарихы, 2нче том, 138-148 бб. Казан, 1985 ел). Шуннан соң аның әсәрләренә багышлап бәя бирүчене хәтерләмим. Туган һәм вафат булган еллары да әлеге җыентыкта күрсәтелмәгән. Ә әсәрләре бит архивларда сакланган. Аларның эчтәлекләре дә шул дәвердәге милләт язмышын чагылдырадыр. Мәсгуд вафат булганнан соң аларны искә алучы юк.

Гомәр Мөхәммәт

Гомәр Мөхәммәт улының күләмле поэма һәм шигырьләре үз заманында бик таралган була. Аның иҗат үрнәкләренең хәзер дә Ташкент белән Петербург архивларында саклануы шул хакта сөйли. Әйе, аның ике күләмле поэмасы Санкт-Петербург мирасханәләрендә дә урын алган, дип белдерә Мәсгуд Гайнетдинов. Шулардан иң танылганнары (һәм сакланганнары) «Тәзкирәи мөфти Габдессәлам» (1154 юл, 1832 ел) һәм «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1878 юл, 1837 ел) икән. Ике әсәр дә Александр I белән аннан соң булачак император Александр II нең Оренбургка килүе, җирле тәртипләр, милләтләр, күрше илдән килгән казах хан-солтаннары белән танышу-очрашуларны чагылдыра. Мөфтият вәкилләренең шул очрашуларны оештыру вакыйгалары тасвирлана, дип яза районлашым Мәсгуд.

Беренче әсәрдә башлыча патша Россиясендәге икенче мөфти Габдессәлам әл Габдерахман әл Бөгелмәви (1774-1840) эшчәнлеге яктыртыла, ди. Ул Оренбург губернасына кергән Габдерахман авылында туган. Әмма ул чорда шундый исем йөрткән ике авыл шул ук губернада теркәлгән. Мөфтинең 1910 елларда Каргалы авылындагы (элекке Сәет бистәсендәге) бер мәчет чормасында табылган үз истәлек язмаларына нигезләнеп, аны Әлмәт шәһәре янәшәсендәгесендә туган, дибез.

Булачак икенче мөфти дә Оренбург янәшәсендәге Каргалы мәдрәсәләренең берсендә укыган. Шул ук бистә мәдрәсәсен тәмамлагач Бохарада укып кайткан Беренче мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов Оренбурда мәчет төзергә патшадан рөхсәт һәм акча алгач, аны Оренбург ахуны һәм булачак мәчет имамы итеп билгели. («Татар әдәбияты тарихы»ның 139 битендә шушы вакыйгага карата түбәндәге мәгълүмат та китерелә. «Габдессәлам Алладан патша күңеленә шәһәрдә мәчет салу уен житкерүне ялварып сорагач, патша казна хисабына таш мәчет төзү боерыгын җибәрә, диелә анда.) Шул рәвешле Оренбургның беренче таш мәчете 1802-1805 елларда сафка бастырыла. (XXI гасыр башында әле ул манарасыз мәчет бинасы да, аның карамагындагы элекке «Вәлия» мәдрәсәсе биналары да бар иде. Бер гасыр элек шул мәдрәсәдә Галимҗан Ибраһимов белән Шәһид Әхмәдиев укыганлыгын хәтерлибез.)

Әлбәттә инде, патшалар тарафыннан эшләнгән мондый «юмартлык»ның үз серләре бар. Урал-Җаек елгасының көнбатыш ярында 1743 елда төзелгән Оренбург каласы да, чирек гасырдан соң шул шәһәрчектә Рәсәйдә яшәүче мөселманнарның «үз» идарәсен – мөфтиятне булдыру да шул сергә бәйле. Олуг дини шәхесебез, мәгърифәтче һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең 1989 елда Казанда нәшер ителгән китабының 209-210 битләренә күз төшерик. «1778 елда Оренбург кальгасында «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла. Бер мөфти, өч казыйдан торган идарә.Беренче мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәен улы, Мансур мулла оныгы—Тау ягының Борындык авылыннан. 1823 ел ахырында ул вафат була, дип яза Ш.Мәрҗани. Шушы ук китапта бу мөфтиятне барлыкка китерүче төп сәбәп тә бәян ителә. Рәсәй белән Төркиянең чираттагы бер сугышы 1774 елда тәмамлана. Урта диңгез буендагы Күчек-Кайнарҗа дигән бер шәһәрчектә шул елның 21 нче июлендә солых килешүе төзелә. Төрекләр ул килешүгә ике җитди параграф өсти. Шул таләп үтәлгән очракта, алар Кырым ханлыгы һәм ярым мөстәкыйль Молдавия, Валахия төбәкләре эшчәнлегенә тыкшынудан баш тартачакларын белдерә. Төрекләрнең төп таләбе – Россиядә яшәүче мөселманнарга берникадәр ирек бирү, үз дини идарәләрен булдыру һәм дини эчтәлекле китаплар бастыруга рөхсәт итү була. Шушы килешүдән соң ук диярлек әлеге мөфтият идарәсе оештырылачак, тәүге Коръән китаплары басылып чыгачак. (Безнең галимнәргә күптән инде бу солых килешүенең эчтәлеген тәрҗемә итеп бастырасы булгандыр.) Дөрес, ул солых килешүенә бәйле хәзерге белешмәләрдә еш кына тәүге таләпләр төшереп калдырыла. Фәкать Кырым ханлыгы белән Молдавиягә кагылышлы параграф кына китерелә.

● Каргалы бистәсендәге Кушманара мәчете.

Әлбәттә инде, патшабикә тирәсендәге түрәләр оештырылачак дини мөфтият идарәсен үзәктән мөмкин кадәр ераккарак урнаштырырга тырыша. Һәм ул «контора»ны чик буенда яңарак кына төзелгән Оренбург каласында оештырырга рөхсәт бирәләр. Урал елгасының аргы ягындагы казах, нугай, каракалпак халыкларын ымсындыру ниятеннән чыгып, чик буенда калка башлаган барлык шәһәрчекләрдә диярлек (Оренбург, Орск, Троицк һ.б.) мәчетләр төзергә, мәдрәсәләр ачарга да рөхсәт итәләр.

Әйе, кайбер очракта казна исәбенә төзеләчәк ул мәчетләрнең язмышы шул күрше дәүләтләр халкы алдында үрнәк булырга тырышудан киләдер. Империя белән идарә иткән «Әби патша» (Екатерина II) Оренбург янәшәсендәге «Меновый двор» бистәсе белән Сәет бистәсе мәдрәсәләрен тоту өчен дә еллык акчалар бүлеп биргән. Һәм шул акча исәбенә казах хан һәм солтаннары балаларын да шунда укыту шартын да куйган була. (Совет дәверендә Оренбург губернаторларына багышлап чыгарылган китапта һәр елны биреләсе ул акчаның күләме дә, ни рәвешле тотыларга тиешлеге дә тасвирлана.)

Минем фаразлавымча, шушы вакыйгалар чорында ук диярлек гомер иткән шагыйрь Гомәр Мөхәммәт улы Каргалыйның әсәрләрендә дә шул заман күренешләре тасвир ителәдер. Совет хакимияте идарәчелек иткән заманда галим Мәсгүд Гайнетдиновның ул әсәрләр белән тулаем таныша алмавы аңлашыла. Мөфти-муллаларга багышланган, шул исәптән патшалар да искә алынган поэмаларның күчермәләрен дә эшләтеп ала алмас иде. Ә хәзер бит ул заман түгел. Командировкага дип бирелгән акча исәбенә дә мирасханәләр ул язмаларны күчереп бирә ала.

***

Патша Александр I нче 1824 елның 11-16 сентябрендә Оренбургта була. Мөхәммәтҗан мөфти вафат булганлыктан, ил башлыгы килгәндә Габдессәлам ахун вакытлыча мөфти вазыйфасын үти, барлык оештыру эшләрендә катнаша. Башкалага кайткач ук Александр I аны рәсми мөфти итеп билгеләү указына кул куячак. Бу вакыйгалар поэмада чагылган, дип яза Мәсгуд әлеге хезмәтендә. «Авторның бу вакыйгага кагылышлы поэмасы Ленинградта – Көнчыгышны өйрәнү институтының кульязмалар фондында В-4089 саны белән саклана. Каталогта автор исеме генә ялгыш теркәлгән: Миргыйният бине Кәрим диелгән», дип яза галим. Мөгаен, Миргыйният ул әсәрне башкалага илтеп тапшыручы булгандыр.

Шул поэмаларның күчермәләрен алып, гамәлгә кертәсе, яңадан нәшер итәсе, автор исе-

бине Каргалый

мен кайтарасы иде. Мәсгуд ул чорда аны эшли алмаган – дин шәхесләрен һәм патшаларны зурлап искә алу тыелган иде ул чорда. Берәр кеше бүген Гомәр Мөхәммәд әсәрләрен үзебезгә кайтару эшенә алынса – үзе өчен дә, әдәбият өчен дә файда булыр иде.

Икенче поэма вакыйгаларына кагылышлы рәвештә классик шагыйрь, булачак император Александр II нең тәрбиячесе, Пушкинның да остазы булган В.А.Жуковский да телгә алына. 1837 елда ул Оренбургка «үз шаһзадә»се белән килә.1940-1950 елларда, без укыган русча һәм татарча дәреслекләрдә Жуковскийның энисе «турчанка Салиха» була дип язылган иде. Ул алпавыт утарында гади хезмәтче булган («была ключницей»), шагыйрь шул алпавыт улы, дип белдерелде ул дәреслекләрдә. Бу вакыйга элекке Касыйм ханлыгы җирләрендә барганлыктан, Салиханың, чынлыкта, татар кызы икәнлеге аңлашыла. Сталин вафатыннан соң чыккан хрестоматия һәм энциклопедияләрдә Салиханы искә алмыйлар инде. Үз йорт-утарларында хезмәт итүче кыз балаларны төрлечә мыскыллаган алпавытларны шул рәвешле аклау-яклау дәверен кичерәбез хәзер.

Шагыйрь Карл Брюллов та 1914 елгы «Нива» журналында чыккан бер истәлегендә Урал якларында туган анасын татар диясе урынга «турчанка» дип язган. «Анам бик шигъри җанлы шәхес иде. Мин аның дәвамчысы», дигәнрәк сүзләр өстәп, анасын мактап та искә ала ул. Ә менә «татар кызы иде ул» дип язмый. Чит ил кешесенә – «турчанкага» тиңләп, анасының татар милләтеннән булганлыгын белгертмәскә тырыша.

1960 еллар урталарыннан, алпавытларның кырын эшен яшереп калу нияте белән, бай утарында мыскыл ителгән, төрле милләт вәкилләреннән булган ул «турчанка»ларны бөтенләй искә алмый башладылар. Элекке Рәсәй алпавытларының азгынлыгын яшереп калдырырга тырышудыр бу.

Тарихка «Куликово кыры вакыйгасы» буларак кергән, элекке Рязань, Тверь, Мәскәү кенәзләренең үзара килешә алмавыннан килеп чыккан сугышны да бит шул алтмышынчы еллардан бирле татар бәге Мамай өстенә аудару сәясәте бара. Ә 1950 еллар урталарынача чыккан дәреслекләрдә исә ул вакыйганы оештыручыларның башында Рязань кенәзе Олег булган. Тверь кенәзе Михаил белән алар нәсел шәҗәрәсе буенча алардан түбәндә торган Мәскәү кенәзенең Бөек кенәз буларак билгеләнеп, алардан өстен чыгуына килешмәгәннәр, дип яздылар. Совет чоры тарихчысы В.Рыбаков исә кенәз Дмитрийның алардан өстен чыгуын дин башлыгы митрополитка бәйле рәвештә аңлата. Алтын Урданың гаскәр башлыгы Мамай тарафыннан җибәрелгән гаскәри берәмлекне бу вакыйгага җәлеп итүче, яллаучы кенәз Олег була. Ә Литва кенәзе Ягайло тарафыннан җибәрелгән гаскәри берәмлек исә кенәз Михаил тарафыннан оештырылган, диелә иде элеккерәк заман китапларында. Аның кыз туганы Ягайлода кияүдә була. Әмма Ягайло җибәргән гаскәр билгеләнгән вакытта булачак яу кырына килеп җитми – ярты тәүлеккә соңлый. Шул сәбәпле Куликово кырында зур сугыш булмыйча кала, гаскәрләр төрлесе төрле якка таралыша, дип язылган иде без укыган еллардагы дәреслекләрдә. (Берничә еллар элек Белорусия галимнәре кенәз Ягайло җибәргән белорус гаскәриләренең ни сәбәпле соңлауларын да ачыкларга тырышты бугай.) Ә 2004 елда Мәскәүдә «Наука» нәшриятында чыккан бер тарихи җыентыкта да вакыйгаларның шулайрак булганлыгы тасвирлана. «Рождение мифа» дип бәяләнгән хезмәтендә тарихчы галим А.Е.Петров «Куликово кыры» вакыйгасын шул хәл булганнан соң йөз ел үткәч, Дмитрий Донскойның варислары тарафыннан оештырылып язылган «Сказание о Мамаевом побоище» китабына нигезләнеп тасвирлыйлар. Аңа чаклы йөз ел элек язылган берничә елъязмада теркәлгән фактлар да, шул язмаларга нигезләнеп иҗат ителгән «Задонщина» китабындагы вакыйгалар да исәпкә алынмый, дип белдерә. Һәм шул элекке елъязмалардан автор аерым фактларны китерә. Ә Мамай бәк исеме белән аталган китапны язучыларның төп максаты Дмитрий Донскойны һәм аның варисларының данын күтәрү өчен генә эшләнгән. Анда 1380 елда булган вакыйгалар бозып тасвирланган, ди автор. Һәм шул фикерен дәлилләр өчен автор күпсанлы мисаллар китерә.



Каргалыда XVIII гасырда төзелгән Ак мәчет.

* * *

Әнисе татар милләтеннән булган шагыйрь В.Жуковский, мөгаен, беркадәр татарча да аңлагандыр. Һәрхәлдә, аның Гомәр Мөхәммәт поэмасының кайсысындыр тәрҗемә иткәнлеге, яки шуңа омтылганлыгы турында элегрәк Оренбург картлары сөйли иде. Шагыйрьнең язмаларында бәлки ул факт та теркәлгән булгандыр. Әмма кайсы телгә тәрҗемә иттерәсе булган? Русчагамы яисә берәр Европа теленәме? Бәлки үзе тәрҗемә итмичә, үзе дә катнашкан вакыйгаларны чагылдырган поэманы кемнәндер башка телгә тәрҗемә иттерәсе килгәндер. Шул хакта Гомәр Мөхәммәтнең икенче поэмасы кулъязмасында хәбәр юкмы икән? Мәсгүд ул поэманың Александр II гә бүләк рәвешендә җибәрелгәнен, шул ук Ленинград институты фондында В-325 саны белән сакланганын хәбәр итә.

В.Жуковскийның әлеге сәяхәткә багышлы үз язмасы 1902 елда «Русская старина» журналында басылган икән. Әмма Казан китапханәләрендә ул санның югалган. Берара университет китапханәсе директоры вазыйфасын Җәүдәт Миңнуллин башкарган иде. Миркасыйм Госмановка шушы вакыйгаларны сөйләгәч, ул миңа Җәүдәткә мөрәҗәгать итәргә киңәш иткән иде. Җәүдәт: «Мин ул бүлек кешеләренә әйтермен. Ике-өч көннән соң кил. Ул журналны тапсалар – укып чыгарсың», диде. Кабат килгәч: «Ул сан табылмады шул. Кемдер аны алып торган да, китермәгәндер», – дигән иде. Ул журналны эзләп Мәскәү тарафларына барып йөрелмәде инде...

Гомәр Мөхәммәт улы Каргалыйның Петербург белән Ташкент архивларында сакланган әдәби мирасының күчермәләрен эзләп алган очракта, әлеге саннардагы истәлек белән танышу да файдага булачак.

Лирон ХӘМИДУЛЛИН.

Самара хәбәрләре

Дошманнар фельетоны

Танылган дин эшлеклесе, Самара шәһәренең Малый Тупик урамы 127 санлы йорт адресы буенча урнашкан мәчетнең беренче имамы Ибраһим Ганиевнең вафатына 55 ел булды. Кызганычка, муллаларны эзәрлекләү очраклары һаман ачыклана тора. Самара өлкәсенең фәнни китапханәсендә, мәсәлән, Ибраһим Ганиевтән ачы көлгән фельетон табыла. Бу «әсәр» бигрәк тә яшьләргә 1960 елларда дингә нинди караш булганын, имамнарның нинди мыскыллауларга түзеп, үз вазыйфаларын башкарганнарын белү өчен файдалы. Фельетоннан бер генә өзек китерү дә җитә:

«Коран, как источник невежества и мракобесия, выдается за священную и чудодейственную книгу. Проповедники всячески поощряют прочтение «от корки до корки», а то и неоднократное, этой объемистой книги в несколько сот страниц у постели больного или во имя исполнения желаний верующего. Невероятный галдеж десятка чтецов, вслух читающих каждый свой раздел, выдается за священный ритуал. Знали бы эти одурманенные мамаши, о чем читают эти «лекари» возле постелей их больных их детей. Невдомек им, признаваемые «священными» на самом деле рассказывают о долговых обязательствах, купле-продаже и прочей ненужной чепухе. Читаются и бесстыдные описания интимных сторон жизни супругов...»

Дин эшлеклесенә пычрак аткан «язучы» аның хатыны Фатыйманы да, сәдака җыеп акча эшләүдә иреннән калышмый, дип каралтып язган. Муллаларның бөтен эше – акчы җыеп ялган сөйләү, янәсе. Ганиевләр генә түгел, Куйбышевның (Самараның элеккеге исеме) Октябрь районында Хәйрулла Гыйльманов та, Чапаевскта Габдулла Вафин да Аллаһ исеме белән акча каера, дип зәһәрен чәчүне дәвам иткән автор.

Фельетон 1964 елның 17 ноябрендә «Волжская комунна» газетасында басылган.

И.Ганиев катнашында узган мәҗлесләрнең нечкәлекләренә кадәр сурәтләнүе, фельетонны ул мәҗлесләрдә катнашкан, мулланы яхшы белгән кеше язган, дип уйларга нигез бирә.

«Язгы тамчы»

Ижевск шәһәрендә татар-башкорт көйләрен башкаручыларның төбәкара «Язгы тамчы» инструменталь фестиваль-конкурсы үтте. Талантлы балаларны барлау, татар музыка сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, милли мәдәниятебез, сәнгатебез дөньясына әйдәүне максат иткән бәйге быел 25 нче тапкыр узды. Аны Удмуртиянең Милли сәясәт министрлыгы ярдәме белән Татар иҗтимагый үзәге оештырды. Быел конкурста катнашу өчен Ижевск, Воткинск, Глазов, Можга шәһәрләреннән, Әгерҗе районыннан 60 тан артык җыр-сәнгать сөюче бала килде. Катнашучылар арасында татарлар гына түгел, ә бәлки рус, удмурт милләтеннән дә балалар булуы татар җыр сәнгате белән кызыксынуның зур булуын күрсәтә. Чаранның ел саен көтеп алына торган конкурска әверелүе исә Татар иҗтимагый үзәгенең генә түгел, ә ата-аналарның, укытучыларның һәм балаларның уртак тырышлыгы нәтиҗәсе. Шунысы әһәмиятле: 25 тапкыр узган конкурста барлыгы 7 меңнән артык бала катнашкан, аларның күбесе үз тормышларын музыка белән бәйләгән. Яшь музыкантлар быел да баян, аккордеон, флейта, фортепиано, саксофон, кларнет һәм башка төрле музыка уен-коралларында моңлы көйләребезне яңгыратты. Быелгы конкурсның үзенчәлеге – анда кече яшьтәге балалар аеруча күп катнашты. Әлбәттә, бу гаиләдә татар көйләренә мәхәббәт тәрбияләнүе белән дә бәйледер. Чөнки өйләрдә татар көйләре яңгыраса, татар җырлары башкарылса, ул балалар киләчәктә үз мәдәниятләрен, сәнгатьләрен онытмый.

Балалар сынатмады. Дулкынланулары, борчылулары сизелсә дә, уен коралларында тырышып, һәркемнең күңеленә үтеп керердәй итеп уйнадылар. Кем өчендер бу беренче тәҗрибә иде. Ижевскидан Әдил Ногуманов музыка мәктәбендә әле беренче елын гына шөгыльләнә икән, баянда уйный. «Минем бабай да баянда уйный иде, өйдә әнием дә һәрвакыт татарча җырлар тыңларга, үзе дә җырларга ярата. Өйдә баян булгач, эти-әни мине музыка мәктәбенә бирергә булды. Миңа бик ошый. Татар көйләрен өйрәнергә, уйнарга, аеруча яратам. Конкурста беренче тапкыр катнашуым, шуңа күрә уйнаганда бик борчылдым, – диде ул. «Асылъяр» ансамбленә йөрүче Никита Медведев конкурста беренче елын гына катнашмый, аның тәҗрибәсе зур. Ул, баянда оста итеп уйнап, барлык тамашачыны таң калдырды. «Асылъяр» ансамбле «Әпипә»не башкарды, курайда «Су буйлап» көен яңгыратты. «Язгы тамчы» конкурсында катнашу безнең өчен горурлык та, шатлык та», – диде коллективка йөрүче Ләйсән Шәрипова.

13 яшьлек, тумыштан дөм сукыр Тимур Нурмөхәммәтов фортепианода уйнаганда, зал тып-тын калды, күпләрнең күзләре яшьләнде. Тимур узган ел төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнаша башлаган. Казанда узган «Жаворонок» халыкара конкурсында Гран-при яулаган. Җыр-сәнгать бәйгесендә һәр катнашучыга да лаеклы урыннар бирелде.

Эльвира ХУҖИНА.
«Яңарыш» газетасы.

ИРАДА

Әкбәр КОШАЛЫ

(Дәвамы. Башы 26 нчы санда.)

«Коронавирус» яки COVID-19», халык телендә «Җәвид-19» безнең күзне ачты, зирәкләндерде, туганлаштырды, безне мәрхәмәтлерәк итте. Мин Ираданың һәрбер хәрәкәтендә, сүзендә, карашында мәгънә эзләдем һәм таптым. Әйтерсең, бу күзгә күренми торган нәмәрсәкәй вирус түгел, ә безнең очрашу мөмкинлеге, кавышу сәбәбе.

Гаҗәп, кайчандыр Ирада «улыбыз туса, Җәвид дип исем кушабыз», дигән иде. Ираданың «Мин әнием кебек иртә үлсәм, оныкларны күрми калам», диюенә, мин «Курыкма, безнең нәселдә

иртә үлүчеләр юк», дип тынычландыра идем.

Эх, фани дөнья!...

Кызык, ул минем Ирада исемле кызым барын беләме икән? Курсташларыннан кем белән хәбәрдә тора икән? Шулкадәр күп сораулар, ә җаваплар юк. Коронавирус белән дә шулай ук.

Тәбризгә барып кайту бер сагышны бетерсә, хәзер икенче сагыш, нииндидер үзенчәлекле сагыш башланды. Теге сагышның тамырлары Тәбриздән, эти ягыннан иде. Күңелемнең бер сагыштан икенче сагышка булган озын юлы, ә коронавирус аны тагын да озынайтты, ахырына якынлаштты. Мин үзем дә аңлата алмаган хисләр дөньясында идем.

Үз истәлекләремнең хуҗабикәсе белән күзгә-күз очрашып торсам да, алар минем күңел төбендә, аның иң караңгы почмакларында саклана иде, Аллаһ Тәгалә минем кулымны Ирада кулына тоттырды. Мин Ирада белән сөйләшсәм дә, кем белән сөйләшкәнемне аңлап бетерә алмый идем. Әллә Ирада, әллә Аллаһ Тәгалә? Пышылдаумы, әллә җанның ачыргаланып кычкыруымы? Аңың йөрәктән йөрәккә күчүеме? Эх, белергә иде!

– Ирада, мин үләм!..

– Кая синең ихтыяр көчең?!

– Нәрсәгә миңа ихтыяр көче, минем Ирадам булмагач.

– Ихтыяр көчең булса, Ирада да синеке булыр...

Без сөйләштек микән, әллә сөйләшмичә генә аңлаштыкмы? Әллә бу миңа күренде генәме? Без кулларыбызны тотыштык кебек. Ләкин бу мөмкин түгел, без баштанаяк киенгән, ә ни өчен ул миңа «Шагыйрь» диме? Ни өчен мин аңа «Таҗлы бикә» димим? Без бит бер-беребезне шулай атый идек.

Кайчандыр Ирада яшьләр һәм студентлар арасында шахмат ярышларында җиңгән иде. Аның башына купшы таҗ кидерделәр. Мин сокланудан аны «Таҗлы бикә» дип атадым. Ул да бурычлы калмады, мине «Шагыйрь» дип атады. Аның кулында минем «Кичәге кичәдә калды» дигән шигырем басылган газета иде. Дөресрәге, ул «Минем Шагыйрем» диде, бигрәк тә «минем» сүзенә басым ясап. Мин эредем. Ираданың үз-үзен тотышына карап, аны төрле исемнәр белән атый идем. Үзен кырыс тотканда – Офицер, күңеле йомшаганда – Җанкүз, кыек караса – Йолдыз күз, ә хәзер – Ирада Таҗлыбикә.

Без баштанаяк шундый махсус киемнәргә киенгән, вирус кына түгел, хәтта хисләр дә бер-беребезгә күчә алмас кебек. Ләкин без бер-беребезне күрмәсәк тә, бер-беребезнең кулларын тотмасак та, шулкадәр көчле, каршы торып булмый торган бәйләнештә идек. Без үзебез бик сизгер хисүткәргечкә әйләндек, нииндидер шатлану да бар иде. Аһ бу җан! Мәхәббәт үтә алмаган киртәләр, ул ача алмаган ишекләр буламы соң? Билгеле, юк!

Без бик тәэсирләнгән идек, хәтта һава җитми. Нииндидер бөркүлек.

Элек, кайчандыр без бергә чакта, безнең тормыш гөрләп торганда, без бер-беребезгә юклы-барлы, буш СМСкалар җибәрә идек. Ә хәзер мин авыртудан шыңшыйм.

Ирада мине сулау аппаратына да кушты, үзе дә минем өчен һава кебек иде. Мин үземнең хәлсезлегемнән, көчсезлегемнән бик тартындым. Мин бит күреп тордым – махсус кием, «скафандр» аны нык йончыта, хәтта күзләре кызарган, бите зәңгәрләнгән, куллары сөялләнгән. Режим бозылган, йоклау кая туры килсә шунда, коридорда, еш кына минем койка белән янәшәдә, урындыкта. Табибләр дә, авырулар да Ирада исеме белән саташалар иде.

Ираданың гамәлләре табиблектән югарырак иде. Болар бары да минем өчен генә идеме, әллә барлык авыруларга да кагыла идеме? Минем беренче вариантка бик ышанасым килә иде.

Алай да, болай да болар Ираданың табиблек һәм кешелек сыйфатларының югары дәрәҗәдә булуын күрсәтә торган билгеләр иде. Ул үзенең бөтен асылы белән Ирада иде. Ирада – алтын йөрәк! Минем таҗым! Кулларыңны үбәр идем, бергә булган вакытларда үпмәсәм дә...

Көннәр узды, ә минем өчен гасыр узгандай булды... Ниһаять, аңыма килдем. Миңа кулланылган көчле дәвалау ысуллары кимеде. Менә инде мин чынлап Ирада белән сөйләшәм. Саташып түгел, чынлап! Мине мәхәббәт аякка бастырды. Ирадага булган мәхәббәтем. Ул да мине яратадыр дигән өмет. Ә ул бары бернинди кинаясез елмая. Бөтен җаны белән елмая. Бәлки, мине җәлләгәнен күрсәтмәскә теләгәндер? Әллә соң мине тынычландырырга тырыштымы? Без бер-беребезгә мөнәсәбәтне башкаларга күрсәтмәдек. Без бер-беребезне кичердек, аңладык һәм узган көннәрдә генә түгел, бүгенгә дә тукталмыйча киләчәк турында сөйләшә алдык. Бер яктан, минем яшьлек көнчелеге, икенче яктан, коронавирус минем күңелемне шундый халәткә китерде ки – мин, озак еллар күрми торсам да, Ираданың гөнаһсызлыгына, сафлыгына һич тә шикләнмәдем. Бу ышану шулкадәр көчле иде. Ирада бик көчле ихтиярлы кыз. Минем Ирадам! Җитмәсә, аның исемен һәрвакыт минем исемем белән бәйлиләр иде. Шуңа күрә балдаксыз йөрү, никахсыз булу безнең өчен зур әһәмияткә ия булмады.

Ә бәлки? Ходаем, үзең сакла! Башкача булырга мөмкин түгел. Башкача уйларга да кирәкми. Кирәкми!

Мәрхүм этием мине сабырсызлыгым өчен гел шелтәләп килде. «Улым, ташла бу каударлануыңны». Ә мин менә элеккечә сабырсызланып, бернинди «кереш сүз»сез ярып салдым:

– Ирада, әйдә өйләнешик!

Сүзләрем ничектер коры, рәсми, колакка ятышсыз килеп чыкты, ләкин сүзне, нишләтәсең, кире алып булмый.

Ирада бөтен йөзен тутырып елмайды:

– Шагыйрь, сиңа «ир» титулы җитмиме?

Мин аның сүзләре ахырында «смайлик» «күреп» калдым – кайчандыр, без язышканда, Ираданың хәбәрләре һәрвакыт смайлик белән бетә иде. Гел күп итеп төрле-төрле смайликлар...

– Мин аңа буш хәбәр юлладым,
Ә ул миңа «Җан» дип язды,
Җансыз телефон экранында «Җан»
Җан кебек күренде җаныма,
җаным өчен.
Җаным минем...

Шигырьгә күп итеп бик күп смайликлар тезгән, нииндие бар, барысын да.

Без хәзер телефонда булмагач, мин Ираданың сүзләрен начар ишеткәнгә, аның самими елмаюын күреп, үзем дә елмайдым:

– Син миңа кияүгә чыгарсыңмы?

– Шагыйрь, син башта аякка бас, бүтән авырма. Аннары карарбыз.

«Карарбыз» дигәндә ул, тирә-якка карап, миңа күз кысты. Бу йөрәгемә сары май булып ятты.

Ниһаять, мин терелдем һәм мине өйгә кайтарып җибәрделәр. Бары да яңадан башланды. Аның «ватсап» номерын белә идем. Еш хәбәрләшеп тордык. Туйдырып, йөдәтеп тә бетергәнмендер. Ләкин Ирада һәрвакыт җавап язды, йә смайлик белән, йә смайликсыз.

Мин гүя яңадан тудым. Сәламәтлек ягыннан да, мәхәббәт ягыннан да. Ә хәзергә, кешеләрнең бу авырудан күпләп үлүен күреп, үземнең туган көнемне коронавирустан терелгән көнемә күчерергә булдым. Ирада, җаным минем, ялкынлы котлау язган. Җитмәсә, икебезгә генә таныш фотоны җибәргән. Ничек саклап калган?!

Моңлы котлаудан соң мин катгый карарга килдем: Ирадага өйләнәм!

Билгеле, бу бик җитди эш, ләкин бүтән тартып-сузып булмый. Күп еллар яратышу, күп еллык газаплар, көн дими, төн дими очрашулар, гөнаһсыз сөешүләр. Ә ул минем тәкъдимемә ни дип җавап бирә?

«Мин сине күрүне гадәт иттем,
Гадәт – мәхәббәт түгел!
Сине күрмәгәндә сагышта булам,
Сагыш – мәхәббәт түгел!
Сине мин ихтирам, хөрмәт итәмен,
Хөрмәт – мәхәббәт түгел!
Күзеңдә чагылган миһербанлыкка
Дәртләнсәм.
Дәрт – мәхәббәт түгел!
Ялварам сиңа,
Мәхәббәт, дим миннән.
Бөтен игътибарым бөтереп алган
Мәхәббәт туфанына
Яшьлегемне
Сиңа корбан итәр өчен
Кире кайтарыймы?! Кире кайтарам...

(Дәвамы киләсе санда.)

Зиннур МАНСУРОВ

АЧЫ ТӘҖРИБӘ КЫСАГА СЫЙМАС



I

● Һәрбер кеше үзенчә хаклы икән, димәк, бөтен җирдә дөреслек хөкем сөрә.

● Үзенең җан авазына битараф бәндә газиз халкының набатларын да ишетмәс.

● Бертөрле генә чәчәкләр үсеп утырган теплица, нинди дер ямансулык тудырып, бердәнбер милләт вәкилләре яшәгән илне хәтерләтә.

● Илбашлар «атом-төш чемоданы»н Изге Китапка алмашса, хәвефле дөньяның бөтен тарафында тынычлык урнашыр.

● Безнең әчтә дөреслекне ярып салган бала утырса, җиһанны иңләп йөрер ялган тәхеткәчә менмәс иде.

● Хакыйкать турындагы рефераттан: «Җирне яссы итеп санаган җаһил чорда ике яклы стандартлар тамыр җәя башлый».

● Төсле инкыйлаб вакытында да кан колориты өстенлек ала.

● Үлеләрдән көнләшү җирлегендә өстенлеккә ирешеп булмаячак.

● Кешенең иреклеккә омтылуы биләүсәдә тыпырчынудан башлана.

● Берничә буынның бәхетле балачагы җәмгыятьне бәхеткә якынрак китерер.

● Мәгълүм демократия өлгесен дини тәгълиматка бәйләмичә куллану ил-йортны башбаштаклык сазлыгына кертеп батыру фаҗигасенә илтер.

● Җиргә түгелгән буыннар каны гыйбрәт алырга һичкайчан җитмәс.

● Хөкүмәт – сабыйга: «Бәхетле балачак өчен салым түләргә әзерлән».

● Бу тормышта четерекле мәсьәлә туа икән, анда һәрбер кешенең азмы-күпме өлеше бар.

● Арткы ишекләрдән керү алга чыгармаска мөмкин.

● Үзеңчә әһәмиятле карарга килсәң, шайтан көләрлек дәрәҗәдә булмасын.

● Кемгәдер каршы дуслашу артында күмәкләп дошманлык кору шәйләнә.

● Салам торхан: «Эшләгән адәмчек хаталанып та куя, шуңа мин ялгышырга бөтенләй теләмим».

● Күкәй эчендәге сары үзен үтә җайлы хис итә, әмма бу рәхәт аның өчен озак вакытлы түгел.

● Эшлекле затларга комачаулык итмәү шайтан ышанмаслык ярдәмгә бәрабәр.

● Акча исе фәкыйрьләрдә аллергия кузгата алмас.

● Милләт авыруы даим сызлата икән, димәк, сине сәламәт итеп санарга мөмкин.

● Канлы сугыш барышын әхлакча көйләп булмый.

● Җәмгыять сәламәт булса, гавам саулыкка кинәнер.

● Әби анай: «Һәрбер затка да хаҗәт ирек чиген кендек бавы белән дә үлчәп була».

● Сәясәт ялганы мизгел эчендә бихисап телгә тәрҗемә ителер.

● Сугышка һичкайчан туп азыгы җитмәгән.

● Кагыйдә кысасын өнәп бетермәүче кавем төрле чыгармалар уйлап табудан туктамас.

● Алдагы елларга ышаныч «иртәгә» сүзеннән башлана.

II

● Алдын миллиятнең зыялый катламы мәдәни мирасны күгәректән саклый.

● Халык чын дирижерны артыннан да таныр.

● Язмыш ханым: «Иң гыйбрәтле китап гамәл дәфтәре булыр».

● Театрда чыккан күз яшьләре күңелгә күп шифа бирүчән.

● Рәхмәткә күнеп эшләүче зат чын зыялы булып саналыр.

● Чамасыз нечкәргән зәвык эчке цензорга әйләнер.

● Өлкән артист егет ролен башкарган чакта аның хатыны эчтән генә аһлап куяр.

● Уртача талант ияләре даһилардан тизрәк танылa.

● Билгесез рәссам эшеннән исемле оста көнләшер.

● Бәгъзе затлар китапларны түгел, учка язылганны ешрак укый.

● Матурлык ямьсезләнешүне өнәми.

● Зәвык кешелекне төркемнәргә бүлә.

● Яшәү сәнгатенең белгечләре азрак.

● Гап-гади чабата үргәндә дә чын сәнгатькә омтылу мәслихәт.

● Даһига остаз кирәкми.

● Азрак күләмдә белем бирүчеләр имтиханда күбрәк мәгълүмат сорар.

● Кангача сеңдерелгән әдәп төрле бозылуга бирешмәс.

● Халык әхлагына пычрак тап төшерү гамәле зурайткыч пыяла аша карап бәяләнергә тиеш.

● Хәйран итәр ахмак гамәлне майтарырга да баш чүмечендә беркадәр акыл булу кирәк.

● Төштә күргән хәл-вакыйгаларны биографиягә өстәп булмый.

● Адәм баласының һөнәри уңышы нәселдә тупланган тәҗрибәгә бәйле.

● Балык башыннан чери, халык теленнән корый.

● Баланың садәлегенә зирәклек кушылып китсә, ошбу тәкъдири тәҗрибә вундеркиндлыкка китерер.

● Тормыш драмасында алмашчылар булмый.

● Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең теше юк – ул сулы стаканга салып куелган.

● Аукционда сәнгать әсәре һичкайчан дөрес бәяләнмәс.

● Үз талантыңны яшереп калу Аллаһ каршында гөнаһлануга тиң.

● Формализм белән чирләүчене киеменә карап каршылыйлар.

● Самими балаларның башына да чын галилек кереп-чыгып йөргәли.

● Кинәт ясалган ачышта элгәрләр өлеше зуррак.

● Хәреф таный белмәгән борынгы зат «И» өстенә ноктаны тизрәк куйган.

● Үзенең тәрҗемәи хәлен хак рәвештә язмаган тарихчы үткәннең серләрен ачканда да ялган өстәлүгә борчылмас.

● Надан булуыңа төшенү аң-белем офыкларын ачар.

III

● Кайбер кешене фәрештәгә тиңләгән чакта, күкнең җирдәге илчеләрен очкылык тотар.

● Мәгънәсез гамәлгә үз мөнәсәбәтеңне белдерү шайтан тегерменәнә су коюга бәрабәр.

● Тәүге имтиханга әзерләнү халәте гомернең соңынача сакланырга тиеш.

● Көндәлек тормышта һәрнәрсәне дә чагыштырып карарга өйрәнсәң, өстеңә ишелгән бәхетсезлек тә җиңеләеп киткәндәй тоелыр.

● Бәла ялгыз гына йөрергә курка, менә шунлыктан алар парлап килә.

● Көндәшеңнең бәлагә таруына әллә ни сөенә күрмә, шушы вакыттан ул сиңа гайрәт-куәт бирүен туктатачак.

● Үзенең бәхетсезлеге белән мактана башлаган кешедә һәртөрле авырлыктан өстенрәк калу омтылышы уяныр.

● Җилбәзәк бәндәгә көенеч килсә, аның йөзендә җитдилек чагылыр.

● Шатлыгың эчеңә сыймыйча алҗыган чакта, елап торучы кешенең кайгысын уртаклаш.

● Ихлас яратып тиргәүнең күңелдә юшкыны калмас.

● Шатлык тышка ташып чыгар, кайгы эчкә үтеп керер.

● Һәртөрле яңа күңелсезлек чиратларны бозып килүчән.

● Күз яшен күрсәтмим дисәң, яңгыр астында елап ал.

● Җанны биләгән һәртөрле өметсезлек куәтеңне тупларга мөмкинлек бирә.

● Шәхсән үзеңә ышаныр өчен дә күп кенә сынауны үтәргә кирәк.

● Беренче очраган кешегә тулысынча ышанып яшә, чөнки кендек әбисе һичнинди шик-шөбһә уятмый.

● Үзеңне тиз инандырыр өчен ныклы тәвәккәллек тә сорала.

● Күңелдә сакланган ният юк-бар гамәлдән өстенрәк.

● Күккә төбәлгән ышаныч һәрдаим биеккә өндәр.

● Бары тик сиңа гына насыйп ителгән өмет йолдызы үзеңне сират күпере башында да күтәп торырга мөмкин.

● Үз-үзеңне җиңәргә кирәк булса, читтән ярдәм сораунга өметләнмә.

● Бүрек белән киңәшү – сәерлек билгесе түгел.

● Дәгъвачы: «Әллә нинди килде-китте сораулары нигезендә психологның үзен кичегүсез дәваларга кирәк».

● Күңел мәтәлчек аткан мизгелдә куеннан ташлар коелып калыр.

● Юләргә сабышкан чакта, гадәтенчә, акыл сатарга ымсынма.

● Ихласлы елмаю йөрәктән башлана.

● Үзеңне үтә хыялый кешегә тиңлә, әмма күләгәң барыбер җиргә елыша.

● Сәламәт тәнеңә җен көче иңсә, аны яхшы эш кылуга файдалан.

● Акыллы зат үз шәхесен «Аңгыра!» дип еш битәрләр.

● Ачы тәҗрибә кысага сыймас.

● Яшәеш мәгънәсенә төшенеп җитү олуг максатны ачыклауга бәрабәр.

Ак җилкәннәр турында хыял

Кариевлеләрнең «Ал җилкәннәр» турында хыялы тормышка ашып, А.Гринның шушы исемдәге әсәре буенча куелган спектакльнең ачык репетициясе булып узды. Премьерасы исә яңа иҗат фасылының 2 нче һәм 3 нче сентябренә билгеләнгән.

Андагы тамашага ис китәрлек. Спектакльнең режиссеры Ренат Әюпов үзе капитан ролендә. Җитмешләп тамашачы сәхнәдә урнашып, тамаша залындагы спектакльне карый. Рәссам Анна Новикова, ут көйләү остасы Евгений Ганзбург, видеограф Максим Кунин, дизайн остасы Сергей Алаев залда могҗиза тудырган. Тамашачының аяк астында гүя чып-чын диңгез җәйрәп ята, ара-тирә утыргычларны ак дулкыннар назлап китә, битләрне саф диңгез җиле үбә сыман. Күз алдында әллә нинди гаҗәп балыклар йөзеп үтә. Иксез-чиксез серле диңгез күренешен тудыруга спектакльнең композиторы Йосыф Бикчәнтәев үзеннән саллы өлеш керткән.

Тамашадан яшьлек рухы бөркелә. Күмәк сәхнәләрдә Казан театр училищесының Лилия һәм Илнар Низамиевләр җитәкчелегендәге беренче курс студентлары катнашуы нәтиҗәсе бу. «Яшьләр турындагы спектакльдә яшьләр уйнарга тиеш. Шул вакытта аларның дәрте, тамашачыныкы белән бергә кушылып, могҗиза туачак», – дип аңлата режиссер Р.Әюпов спектакльдә егермеләп студентны катнаштыруын. Артур Грэй – Татарстанның атказанган артистлары Лилия һәм Илнар Низамиевләрнең улы Искәндәр өчен дебют роле. Кариев театры труппасы тагын бер чибәр, талантлы ир-егет артист белән баеганга күңел сөенә.

Спектакльнең жанры тикмәгә генә феерия дип билгеләнмәгән. Сихри сәхнә күренешләре тудырган рәссамнар гына түгел, режиссер үзе дә жанрның исеме җисеменә туры килсен өчен күп эшләгән. Капитан дисәң дә капитан! Ул күмәк күренешләрнең оста куелуы, хореография, җыр дисеңме... Спектакльне сәхнәләштерүдә Татарстан дәүләт камера хоры җитәкчесе Миләүшә Тәминдарова, Камал театрының оста биючесе буларак яхшы ат алган артисты Артур Шәйдуллин катнашкан.

Төп рольләрне исә Ләйсән Большова һәм Альбина Ногманова (Ассоль), Лилия һәм Илнар Низамиевләр, Илназ Хәбибуллин, Фәнис Кәлимуллин, Фернат Насыйбуллин, Илфат Камалиев, Муса Камалов һ.б. башкара.

Йөрәгеңә тугры калсаң, бөтен хыяллар да тормышка аша, диләр. Кариев командасының хыяллана белүе һәм бернигә дә карамастан хыялларына тугры калуы бу спектакльдә бик яхшы күренә. «Ни өчен кешеләр шундый усал», – дип сорый Ассоль әтисеннән. «Чөнки алар ярата белми», – дип җавап кайтара Лонгрен. Киң күңел белән яратып иҗат ителгән бу спектакль тамашачының күңелен йомшартып җибәрә, заманына күрә кырысланган йөрәген эретә, киртәләрне ярып алга барырлык көч бирә.

М. МӘХМҮТОВА.

Кечкенә авылның зур театры

Саба районында Мишә елгасы буенда Чәбия Чүрчи исемле авыл бар. XIX гасыр урталарына караган мәгълүматлардан күренгәнчә анда 36 хуҗалыкта 255 кеше яшәгән, мәчете булган. Чәбия Чүрчине филолог, библиограф галим Әбрар Кәримуллинның туган авылы буларак та беләбез. Ни кызганыч, бүген анда нибары 35 кеше генә гомер кичерә. Ә иң кызыгы – шушы бетеп барган авылда күп кенә зур шәһәрләрдә дә булмаган марионеткалар театры эшләп килә. Аны ирле-хатынлы Зөлфия һәм Вячеслав Дробатухиннар оештырган һәм җитәкли.

Белгечләрнең әйтүенә караганда, марионеткалар – кешегә иң охшаган курчаклар, шуңа күрә аларны ясавы да бик авыр. Бүген марионетка ясаучы осталар юк дәрәҗәсендә аз. Бу төр курчаклар белән иҗат итәргә дә өйрәтмиләр диярлек. Шуңа күрә марионеткалар сәхнәләрдә күренми. Үзебезнең «Әкият» татар дәүләт курчак театрында да бу төр курчакларны күптән күргән юк иде. Киләсе елга театрыбыз оешканга 90 ел була. Шул вакыт эчендә куелган марионеткалы спектакльләрне бармак белән генә санарлык. Әмма режиссер Илгиз Зәйниев традицияне яңартып, күптән түгел нәни тамашачыларның әти-әниләре өчен репрессияләр чоры турында «Авиатор» исемле бик мәгънәле спектакль куйды һәм ул – республикабызның горурлыгы булган «Әкият» театрында да – бердәнбер марионеткалы тамаша.

Аның каравы, курчак театрында артистлар үзләре сәхнәгә чыгып уйнаган очраклар ешайганнан-ешая бара. Шул рәвешле яңа заман тамашачысының йөрәгенә юл табасылары килә. Ләкин курчак йөртү традициясе югалу бик нык борчуга сала. Белгечләр Казаныбызда узган һәр «Шомбай» фестивале саен бу хакта чаң кага. Курчаклар белән бергә җан юкка чыга. Бүген адәм баласы тере роботны хәтерләткән заманда хәтта театрда җанның югалуы пошаманга сала. Шундый шомлы заманда 35 кешелек Чәбия Чүрчидә сәхнәгә курчакны кайтарырга омтылучыларга шаккатарлык түгелмени?!

Зөлфия Тимергалиева Олы Нырты авылында дөньяга килгән. Мәктәптән соң Алабуга мәдәни агарту училищесына укырга киткән һәм анда Вячеслав Дробатухин белән гаилә корган. Бәхет эзләп Чиләбене урап кайткач, олыгайган көннәрендә алар Саба районында төпләнә. Моннан бер ел элек Зөлфияне Чәбия Чүрчи авылына клуб мөдире итеп билгелиләр. Ире исә Зөлфиябезгә ярдәм йөзеннән марионеткалар театрын оештыра. Үзе ул экономист дипломы алса да, бер көн дә үз белгечлеге буенча эшләмәгән, аннимация белән шөгыльләнгән, видеороликлар төшергән. Хыялый күңелле егет күбәләк кебек очып-очып биюче хореограф Зөлфиябезгә тикмәгә генә тартылмаганы аңлашыла. Анимациядә булган тәҗрибәсе В. Дробатухинга курчак ясау серләренә төшенергә мөмкинлек бирә. Шулай да эш озакка сузыла. Леонид Филатовның халык әкиятенә нигезләнеп язылган «Про Федота-стрельца молодого удальца» исемле тәүге спектакль өчен алты курчакны иртәнге таңнан төн уртасына кадәр тоташ өч ай ясый. Аннары ике атна курчаклар булып сөйләргә өйрәнә.Спектакль күбрәк өлкәннәргә исәпләнгән, чөнки анда сөйгән ярына күзе кызганга күрә, Федотны үтерергә ниятләп, төрле тузга язмаган эшләр кушучы патша турында бәян ителә. Шул рәвешле «Арт-Грате» курчак театрының әнкәсе һәм әткәсе дәүләт башлыкларының комсызлыгын, намуссызлыгын, алдашуын фаш итәргә тели. Балаларга исә курчакларны тотып, җепләреннән тартып каравы кызык. Бу спектакль белән бөтен Саба районын йөреп чыкканнан соң халык әкияте буенча «Вершки и корешки» спектакле өчен курчаклар ясаганнар. Чиратта – Тукаебызның «Кәҗә белән Сарыгы». Иң беренче курчаклары агачтан булса, районның мәдәният җитәкчеләре талантларга ярдәм йөзеннән бераз акча кушкач, полимер балчык куллана башлыйлар. Геройлар камилләшә бара, шул ук вакытта авырлыклары арта. Берәр сәгатьлек тамашаларда алты-җиде курчак белән берүзе идарә иткән һәвәскәргә җиңел түгел. Әмма сөекле хатынына булган мәхәббәте һәм сәнгать хакына барысына да әзер Вячеслав.

«Арт-Грате» театрының тамашасын бер караган балалар, яңа спектакль кайчан куясыз, дип сорап килә башлаган. Чәбия Чүрчи кебек кечкенә авылларга шушындый хыялыйлар җан өрмәсме әле?..

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГҮЗӘЛ АВЫЛЫМ БАЙСАР

(Тарихи китаптан өзекләр)

(Дәвамы. Башы 26 нчы санда).

Документтан күренгәнчә, Байсар авылында бу вакытта инде Гәрәй кабиләсе һәм Буләр уруы вәкилләре яши. Гәрәй волосте старшинасы Кадер-гул Касыймов белән үз олыстaшлары һәм буләрлеләр исеменнән эш йөртүче Мерәс Солтанаев 30 йортта яшәүче йәнәйлеләргә үз вотчиналарына күчеп утырырга рөхсәт бирә. Документ өйдәшләр булып килгән йәнәйлеләр санын вотчина хуҗалары – гәрәйлеләр һәм буләрлеләр күләме белән чагыштырып карау мөмкинлеген бирми. Андый мөмкинлек халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре мәгълүм булгач кына туачак. Ә Гәрәй, Йәнәй, Буләр волостьларының старшиналары һәм авылларга килеп урнашкан крестьяннарның күпчелеге 1738 елга кадәр үк «башкорт вотчиннигы – җир хуҗасы» икәнлекне раслаучы грамота алып өлгергән бит. Авылларның күпчелеген «асаба башкортлар» тәшкил итә икән, аларга җанисәп алып йөрүче чиновниклар керми. Менә шул сәбәпле 1719 елдан башлап 1784 елга кадәр үткәрелгән беренче дүрт ревизия вакытында Минзәлә өязендәге «башкорт» авылларының бик күбесе хисап кәгазьләренә кертелмичә кала...

1746 елның 1 май датасы белән рәсмиләштерелгән документ белән танышыйк. Ул да «Материалы по истории Башкирской АССР» китабының III томында урнаштырылган. «Запись башкир Казанской дороги, Енейской вол. Алдара Уразметова с товарищами крестьянину Казанского уезда, Сарапульской волости д. Глухово об отдаче в оброчное владение на 20 лет своей вотчины по реке Каме» исемендә. Документта Байсарга килеп урнашкан йәнәйлеләрнең, старшина Алдар Уразмәтовка буйсынучы Үтәгән авылы вотчинниклары белән бергә, Кама елгасының уң ягындагы вотчиналарын сарай крестьяннарына 20 елга арендага бирү турында сүз бара. Байсар авылындагы йәнәйлеләр исеменнән Пулат Ирмәшев эш йөртә.

Үтәгән авылы хәзерге Әгерже районында урнашкан. Ул төбәктә Йәнәй волостеның Тугыз (Тугызбуй) түбәсе «башкортлары», Байсар авылына күчеп утырганнарының кавемдәшләре яшәгән. Алар арасында Исәнбай, Касай авылы крестьяннары 1720 елларга кадәр үк «башкорт» таифәсендә саналган.

Байсар авылына күчеп тереклек кылучы йәнәйлеләр турындагы хәбәрләр «Материалы по истории Башкирской АССР» китабының IV том, беренче кисәгендә дә берничә. Аларның берсе, 1754 елның 16 марттагысы белән тулырак танышу кирәктер. Чөнки ул Йәнәй олысының берьюлы биш аймагы вотчинниклары исеменнән төзелгән, анда аймакларга кергән авыллар һәм вотчинниклар исеменнән эш йөртүчеләрнең исем-фамилияләре дә атала.

«№42. 1754 г. марта 16. Запись башкир Казанской дороги, Енейской волости Алдара Уразметова с товарищами Уфимскому купцу И.Ф. Шишковскому с товарищами об отдаче им в оброчное владение на 25 лет рыбных ловель в р. Каме.

Лета 1754-го, март, в шестой на десять день. Уфимского уезду Казанской дороги, Енейской волости старшина Айдар Уразметов, 5 аймаков башкирцы: первого аймаку, деревни Апасевой Муртаза Апасев, деревни Байсаровой Мастай Абызаев, Сююндук Князев, Пулат Ирмашев, Минлибай Ишменев, Ишкиня Азметев, деревни Келтевой Юсупкул Утеков, Муса Казанчев, Солтан Сюянгулов, Девлекей Мратов, Максют Ишменев, деревни Исенбаевой Темир Бухарметев, Исень Балтачев; второго аймаку, деревни Семестровны Чюрагул да Солтан Агишев, Галий Зиянов, Якшигул Toктамышев, Кадыр Юзекеев, Усман Ишкинин, Минлибай Юртокеев, Кутлумметь Елдашев, Утемыш Акчюрин, Ишметь Чирюков, Мурза Кискинин, Адзитер Аднагулов, Мулла Ишкилдин, Мясягут Касимов, Кинзибай Тулунбаев, Арисланбек Шимурзин, деревни Емалы Юмай Иликеев, деревни Буаскул Иманай Асанов, Чюраш Карабаев; третьего аймаку, деревни Каинтюбы Юзей Шигимов, Азметев, Уразман Уразаев, деревни Суыксу Сепер Абдуллин, Сююндук Телдеев, Бадрак Исемметов, Абызай Ишметев; четвертого аймаку, деревни Акузины Ишмурза Исаев, деревни Терпело Мо(с)ков Бекчурин, Кунур Умиров, Козягул Канзегулов; пятого аймаку деревни Семестровны Исенметь Касимов, Булгаир Дюсметов со всеге общего мирского согласия будучи в пригороде Каракулине, дали сию на себя у крепостных дел запись Уфимскому купцу Ивану Федорову сыну Шишковскому, Казанского уезду, Арской дороги, дворцовой Сарапульской волости, села Сарапула дворцовым крестьяном Леонтью Сидорову сыну да Дмитрею Титову сыну Жерноковым в том что отдали мы, Айдар с вышеписанными товарыщи, им, Ивану с товарыщ старинные вотчинные свои воды, Каму реку со старицею каскою...»

Байсар авылында гомер итүче йәнәйлеләр Апач, Исәнбай, Кәлтәү авыллары вотчиналылары белән бергә Старица күлләрен (Әлҗәт-Митау) 12 елга арендага биргән. Ул «Материалы...» китабының IV томы, беренче кисәгендәге 54 нче санлы документ белән раслана. Документ 1755 елның 10 мартында төзелгән, йәнәйлеләр исеменнән эш йөртүчеләр арасында йөзбашы Мастей Абызаев, Мәмәт Исәнбаев, Миңлебай Ишмәнев бар.

1757 елның 1 мартында төзелгән документ Байсардагы йәнәйлеләрнең Апач, Кәлтәү, Семистрау, Суыксу, Шәбез, Әҗби авыллары вотчиналылары белән бергә Сөн елгасы тамагыннан алып Туктар күленә кадәрге арасын 20 ел балык тотарга оброкка бирүләре турында сөйли. Документ «Материалы...» китабының IV том, беренче кисәгенә 92 нче сан белән кертелгән. Документта авыл вәкиле Пулат Ирмәшев исеме атала.

Шул ук китаптагы 156 санлы документ Кыяды (Олы Сагадак) күлен 14 елга оброкка бирү хакында. Ул Байсар йәнәйлеләре, Апач, Исәнбай, Кәлтәү, Суыксу, Терпеле, Шәбез авыллары вотчинниклары исеменнән төзелгән. Байсар авылыннан Сөендек Князев, Миңлебай Ишмәнов, Бакир Ишәлиев, Минтәй һәм Сөендек Мусаевларның фамилияләре аталган. Документ 1761 елның 1 мартында төзелгән.

Шушы урында тукталып, Байсар авылында «башкорт катламы»на язылып яшәүче татарлардан Корыч Ирмәшев, Мостай Йосыфкулов, Баязит Бикчәнтәев, Исергәп Рангуловның 1757 елда Пруссиягә ясалган хәрби походта катнашуы турында да әйтеп үтик.

Моңарчы күздән кичергән документлар оброкка бирелгән Йәнәй волосте җирләре турында булды. Ә чираттагы, 1785 елның 30 гыйнварында төзелгән документ Буләр олысының Зәй елгасы буендагы җирләрен (ә ул биләмә Ләшәү, Кәскә, Ирнә, Ямаш, Олы һәм Кече Урсала, Шарлама кебек кече елгалар буен үз эченә алган) граф А.К.Разумовскийга сату турында. Сатуда Ахун, Иске Сәфәр, Сәет, Елан, Исәмәт, Кадергол (Кадермәт), Сеңрән авылларының вотчиналылары катнашкан. Байсар авылыннан вәкил – Габдрахман Мерәсев. (1738 елда йәнәйлеләрне үз вотчиналарына кабул иткәндә Мерәс Солтанаев булган.) Әлеге сатуалу буләрлеләргә 700 сум керем (табыш) китергән.

Шул ук составтагы вотчиналылар 1785 елның 3 февралендә Зәй елгасы буендагы җирләренең тагын бер өлешен 400 сумга генерал-поручик А.Г.Петров-Соловова сатып җибәргән (Сарман районының Петровка авылын һәм андагы спирт заводын шушы генерал нигезләгән). Торгта Буләр волосте вотчинникларның ышанычлы вәкиле булып Байсар Габдрахманов атлы крестьян катнаша. Кама елгасы буендагы бер биләмәне 1790 елда сарай кинәшчесе Миндияр Бикчурингa сатып җибәргән чагында Йәнәй волосте ышанычлылары исеменнән инде Байсар Абызаев атлы икенче вәкил кул куя.

1793 елның 26 октябрендә буләрлеләр Зәй, Ирнә, Ямаш елгалары буендагы җирләрен майор Д.А.Чирковка 500 сумга саткан...

1795 елгы ревизия сказкалары Байсар авылында 63 йортта яшәгән ике җенестәге 401 «башкорт»ны теркәгән. Шуларның 192 се ир затындагылар. Башкорт таифәсендәгеләрнең 330 ы – өйдәшләр хокукында. Алары йәнәйлеләр. 71 башкорт – вотчина хуҗалары, Буләр олысыннан, Буләр түбәсе «башкорт»лары. 1738 елгы документтан аңлашылганча, алар арасында гәрәйлеләр дә бар. Ләкин алары аерым аталмый. Байсарда шул елда тагын 79 типтәр һәм 6 ясаклы татар гомер иткән. Йомгаклап әйткәндә, авылдагы 80 хуҗалыкта 486 кеше яшәгән.

«Башкирец» булып теркәлгән Байсар ирләре 1771-1773 елларда Россия изүеннән котылу өчен азатлык явына күтәрелгән Польша крестьяннарының восстаниесен канга батырып бастыру походында катнашырга мәҗбүр булган.

1773 елның көзендә Пугачев фетнәсе кузгалгач, Байсар авылыннан 31 ир Минзәлә каласын камалышта тоту өчен барган. 1812 елда илгә Наполеон гаскәре бәреп кергәч, байсарлылар патша

● Минзәлә сәүдәгәре Андрей Попов Байсар авылында 1904 елда төзеткән кибет.

фәрманы буенча оештырылган «башкорт» полклары составында Ватан сугышы бәрелешләрендә һәм Париж каласын яулап алуда да катнаша. Мәчти авылыннан гаскәри йөзбашы дәрәҗәсендәге 25 яшьлек Габделхалик Шәрип углы Айдаров 1805 елда ук 3 нче «башкорт» полкы составында Европа дәүләтләренә юл тота һәм Аустерлиц каласы янында французларга каршы бәрелешләрдә катнаша. Байсарның зауряд-хорунжий дәрәҗәсендәге 20 яшьлек егете Габидулла Мөсәгыйт улы Миндәев 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армия белән походларга йөри. Мәчти авылыннан 24 яшьлек зауряд-хорунжий Хәйбулла Ишкилде улы Шыгаев 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армиядә була, Европа походларында катнаша. Соңыннан һәммәсе дә 1812 ел һәм Парижны алу истәлегенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнә...

1834 елда Байсар авылында 108 йортта гомер итүче 575 кеше «башкорт» катламына иңеп өлгергән. 1848 елда 109 хуҗалыкта яшәүче «башкортлар» саны 629 га җиткән (алардан тыш авылдагы 41 йортта 200 типтәр вәкиле дә яшәгән). 1870 елда 182 хуҗалыкта гомер итүче 807 «башкорт» исәпкә алынган.

Байсар авылы халкының көнкүрешен сурәтләп алу да кирәк. 1840 елда авылдагы 565 «башкорт» 13450 сутый мәйданда көзге һәм 17600 сутый җирдә язгы чәчү үткәрә.1848 елда 109 «башкорт» хуҗалыгында 562 баш ат, 316 сыер, 412 баш сарык, 355 баш кәҗә исәпләнә. Шул ук крестьяннар 100 гә якын умарта оясы тота. Алардан тыш 41 типтәр хуҗалыгы 188 баш атка, 178 сыерга, 172 баш сарыкка һәм 128 кәҗәгә, 43 умартага ия була. Шул ук 1848 елда авылда тегермән эшли, ә 1870 елда Иске Байсарда гына 16 төрле кибет, өстәвенә атна саен базар-ярминкә, волость идарәсе эшләп тора.

1858 елда үткәрелгән чираттагы X нчы ревизия вакытында авылда 1165 кеше яшәгән булса, 1870 елда ул 358 кешегә кимеп, 807 кешегә калган. 1884 елгы мәгълүматлар торак пунктында 1712 кеше исәпкә алынган булуын белдерә. 12 ел эчендә халык санының 358 кешегә кимүе – 1870 еллар үрендә хәзерге (Иске) Байсардан аерылып, Сөн елгасы буйлап ике чакрым югарырак агымга күченгән Яңа Байсар һәм бүгенге Яңавыл районындагы Биз елгасының ике як ярында яткан яланда янә бер, исемен үзгәртмәгән Байсар авылలары барлыкка килү белән бәйле. Берничә дистә гаилә кешеләренә «башка чыгудан» – аерылып китүдән башка чара да калмагандыр. Чөнки Байсар крестьяннары, асылда, чәчүлек җир җитмәүдән җәфа чигә башлый. Авылдагы Бикмөхәммәт, Төхбәкәй, Зариф, Шәйдулла, Шәймәрдән, Әмирхан мулла, Өммегөлсем атлы тол хатын кебек байлар иң уңдырышлы йөзәр дисәтинә басуга хуҗа булып ала. Халык, чәчүлек җир эзләп, Алкаби һәм Чәүкә таулары арьягындагы моңа кадәр сөрелмичә яткан яланнарны файдалана башлый. Ә бу исә, үз чиратында, якындагы Исәмәт, Җәйләү, Кадер, Сеңрән авылы крестьяннары белән бәрелеш китереп тудыра. Нәкъ шул 1870 елларда Кадер авылы кешеләре алар ягында иген чәчеп йөрүче Габделхак атлы крестьянны әләктереп, аны вәхшиләрчә кыйнап үтерә. Шуннан ары Байсар халкы хәзер Каравыл тавы дигән исем белән билгеле биеклек өстенә чират буенча каравылчылар да куя башлый...

1866 елда Байсар авылы волость үзәге итеп билгеләнгәннән соң, аңа якын-тирәдәге 32 авыл буйсына башлый, ә анда барлыгы 20330 җан иясе, күпчелеге «башкорт катламы – җир хуҗасы» булып язылган крестьяннар яши («Аулы...», 252 бит).

1896 ел мәгълүматлары белән төзелгән ике белешмәлек ике төрле хәбәр бирә. Аларның берсе авылда 1689 кеше яшәвен белдерсә, икенчесе бу санны 1824 кешегә җиткерә.

1905 елгы Беренче рус революциясе белән бәйле вакыйгалар да Байсар халкы хәтерендә мәңге җуелмаслык эз калдыра. Шушы революциядә катнашкан өчен Минзәлә төрмәсенә ябылган Михаил Кадомцев һәм Адам Головин атлы ике большевик 1908 елның җәендә зур әзерлекләрдән соң, төрмә тарихында бердәнбер очрак кылып, зинданнан качуга ирешә. Ялланган атларда Уфага төбәп барган качакларны Байсарда стражниклар куып җитә. Ике арада башланган атыш вакытында Головин шундук һәлак була, авыр яраланган Кадомцев, авылдагы Шәйхеразый Фәхразиев атлы томана крестьян бакчасына кереп, бәрәңге сабаклары арасына яшеренергә исәпли. Ләкин Шәйхеразый, качак кешене карак дип уйлап, аның башына көрәк белән суга. Һушсыз яткан революционер, кулга алынып, Уфа төрмәсенә озатыла. Ә авыл читенә күмелгән Головин кабере һаман Актаныш юл читендә япа-ялгыз көе тора әле...

● Татарстан делегатларының ВКП(б)ның 1934 елның 18-21 декабрендә узган XIV съездында Сталин белән бергә төшкән сурәте. Утырганнар (сулдан уңга): И.В.Сталин, К.А.Рахтенин, М.М.Хатаев, Я.Д.Чанышев. Басып торалар: Х.З.Габидуллин, Д.Е.Бендюков, Ш.Ш.Шәймәрдәнов, А.М.Вахитов.

1906 елда авылда халык саны 2034 кеше булса, 1913 елда – 2038 кеше яши. 1912 елның кышында йорттан-йортка йөреп үткәрелгән хуҗалык исәбе Иске Байсар авылы лапасларында 3 мең баш сарык һәм кәҗә, 642 баш ат, 603 баш сыер тотылуын ачыклый. 21 гаилә 86 оя умарта тота. Ә авылдагы 224 кеше промысел белән дә шөгыльләнә, ягъни йә үз хуҗалыгында сату өчен нидер җитештереп, йә читтәге тазарак, хәллерәк тормышлы гаиләләргә, урман кисү, сал агызу, пристаньнарда йөк төяү һәм бушату, байларга товар ташуда ломовой сыйфатында ялланып, көн күрердәй акча эшләп кайта.

55 мең булып сугышка китүче минзәләлеләр арасыннан 1914-1916 елларда 2288 ир-ат – Байсар, 2074 кеше – Семиостров-Өшәр, 1554 рекрут – Пучы, 925 егет – Такталачык, 72 кеше Актаныш волостеннан озатыла. Ә барча сугыш дәвамында өяздәге һәр авыл уртача 135 улын солдатка озата. Ни үкенеч, хәтта шушы сугыш архивлары да тулысынча ачылмаган, шул сәбәпле һәр солдат язмышын тулысынча һич тә белә алмыйбыз. Ә сугыш корбаннарсыз булмый. Әйтик, Минзәлә өязеннән 26 солдатның Беренче бөтендөнья сугышында газ белән агуланып һәлак булуы билгеле (ул тулы исемлек түгел). Алар арасыннан 220 нче Скопинск пехота полкында хезмәт итүче Байсар волосте егетләре Мөхәммәтхәлим Тимергалиев белән Ялчыгол Хәкимуллин, Пучы олысыннан Бәдретдин Садретдинов һәм Мөхәммәтдин Әхмәтҗанов, Яңа Семистрау авылыннан Зиннәтулла Гыйззәтуллин 1915 елның 24-25 июнь көннәрендә Польшаның Доловатка хуторы янында якты дөнья белән бәхилләшә. Фронттагы яуларда минзәләлеләрдән 210 батыр төрле дәрәҗәдәге Георгий тәреләренә лаек була. Иске Байсардан Шаһимәрдән Мөхәммәт улы Солтанов, Миңлехаҗи Җамалетдинов һәм Хәйрулла Хөрмәтуллин 4 нче дәрәҗә Георгий тәресе кавалерлары булып кайтуга ирешә. Сугыш кырыннан Хәйбулла Шакиров, Габдулла Солтанов, Шәйхеразый Фәхразиев, Мирзамәхмүт Мөхәммәдиев, Шәрифҗан Хөсәенов, Фәхрислам Исламов, Исмәгыйл Галиев һәм тагын дистәләгән байсарлы исән-имин әйләнеп кайта.

Бәрелеш-кырылышлар фәкать бер якның гына югалтулары белән бармый. 1915 елның 29 мартында Чаллыдан Минзәләгә 1100 немец әсирен куып китерәләр. Аларның 200 гә якыны Чаллы элеваторы төзелешендә (1917 елның 4 сентябрендә ачыла), калганнары авыл хуҗалыгы тармагында эшли. Менә шуларның бер өлеше Байсар авылында прораб Шәйхетдин Корбангалиев җитәкчелегендә туберкулез диспансерының бик шәп биналарын да төзеп куя. Немецлардан тыш, Минзәлә өязенә Россия империясенең көнбатыштагы чик буе районнарыннан 5123 кеше күчереп утыртыла, аларның 750 се Такталачык волосте авылларында гомер сөрә...

1917 елның 25 октябрендә – Казанда, ә 14 декабрьдә Минзәләдә хакимият Совет власте кулына күчә. Октябрь инкыйлабыннан соң кузгалган Гражданнар сугышы Иске Байсар авылының да астын-өскә китерә. Беренче бөтендөнья сугышы барышында, окопларда чагында ук большевиклар партиясенә язылган, фронтта ике дошман гаскәр арасында корал ташлап «туганлашу» акцияләрен үткәрүдә, Михельсон атлы очлы күзле «остаз» белән бергә үз полкында большевиклар ячейкасын оештыруда бай тәҗрибә туплаган Шәйгәрдән Шәймәрдәнов 1918 елның 22 гыйнварында Байсарга кайтып төшә. Аңлыйсыздыр, аеруча авыл җирлегендә нинди дер яңа власть, яңа түнтәреш кешеләренә каршы күтәрелеп, бугаз яручылар меңәрләп табылмый бит. Крестьяннар да, билгеле, үзләре күләгәдә калып, башка «ташбашларны» ут астына кертү ягындарак. Менә шундый күршеләр вә яшьтәшләр котыртуы белән Шәйгәрдәнне волостьның җир эшләре буенча махсус комитетына сайлап куялар. Ә муенына камыт кидеңме, дәрәҗәле «постны» акламыйча да булмый. Шәйгәрдән кайткан чы волость советы рәисе булып торган Каюм Сөендеков, тагын Хөсәен Нуриев, Әбугали Әхмәтов, Габдрахман Мирзаһитов, Шәех һәм Хуҗагали Тимергалин, Рәхмәтулла Кисрәев-Баширов кебек ярдәмчеләр табып, Шәйгәрдән әүвәл бай кулак саналучы Хәсәнов, Гыйләҗетдинов шикелле байлардан җир талап алып, аларны хәерче крестьяннарга өләшүне оештыра. Шушы ташбашлыгы өчен Шәйгәрдәнне 1918 елның мартында Иске Байсар авылында большевиклар хыялланган властьның авыл советы рәисе итеп сайлап куялар. Шәйгәрдән башлаган кыюлык турындагы хәбәр волостьның 32 авылы буйлап тарала. Кормаш, Бикчәнтәй, Урәзмәт, Апач, Солтангол, Сикия кебек авылларда да байлар җирен ярлы крестьяннарга өләшәләр. Ә бер тишелеп чыккан бодай яки арпа барыбер үсми калмый, дигән сыман, 1918 елның июнендә Шәйгәрдән инде советлашкан волостьның башкарма комитетын да, хәрби комиссариатны да җитәкли башлый. Авылларда да байларның һәм кулакларның җирләрен тартып алып, аны өр-яңадан бүлү үткәрелә. Һәр крестьянга 1,36 дисәтинә чәчүлек җир һәм 0,2 дисәтинә болын эләгә, ләкин аның файдасын күрергә өлгермиләр, 1918 елның 20-25 июлендә Уфа ягыннан Байсарга ак чехлар басып керә.

Сүз дә юк, үз карамагындагы совет властен саклап калу өчен Шәйгәрдән дә тиз арада Байсар авылында беренче чиратта март аенда җир бүлешүдә катнашкан крестьяннардан Кызыл гвардия отряды туплый һәм Бакалы белән Яркәй, Дүртөйле ягыннан килеп чыккан чех һәм акгвардиячеләргә каршы тора башлый. Минзәләдәге өяз комитеты башлыгы Федор Митюшкин да аның кул астына 20 җайдак сугышчы озатып ярдәм кулын суза. Шәйгәрдән Байсарда үзе дә Мәүләү Шәкүров, Галимҗан Мостафин, Мәүләү Якупов, Тимергали Фәсхетдинов кебек крестьяннарны үз отрядына туплый.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Алтын Урданың

«Болгар чорыннан башка татар тарихы була алмаган кебек, Алтын Урда тарихыннан башка да аның булуы мөмкин түгел!» – дигән сүзләр хәзер торган саен кыюрак яңгырый. Алтын Урданың Европа һәм Азия киңлекләрендә төпләнгән барлык төрки халыкларны берләштергән һәм бөтен дөньяга цивилизация үрнәкләре күрсәтеп яшәгән бөек татар дәүләте булуы турында хәзер саллы фәнни хезмәтләр басыла. Ни кызганыч, тик әлегә татар халкында үзенең тарихына хөрмәт һәм аңа карата горурлык уята алырлык популяр әсәрләрнең күренгәне юк.

Элгәре Алтын Урда тарихын каралап килгән сәясәтнең кайтавазы һаман да күпләрне шикләндерә һәм бу темага ныгытып кагылырга да чиркандыра сыман. Ә чынында Алтын Урданың тарихы бөек тә, гыйбрәтле дә, шул ук вакытта ул фаҗигале һәм үкенечле дә.

Барлык империяләрнең язмышы атылган йолдызлар сыман. Тик күктәге йолдызлар атылгач, аларның эзләре сүнеп югалса, төрки империяләрнең эзе мәңгелек. Алтын Урданың эзе шундый ук. Изелгән-имгәтелгән булса да, аның тарихы гыйбрәтле. Тик андагы күп нәрсә әле үзен ныгытып ачыклауны, ялганнардан арынуны көтеп ята.

Чыңгызхан үз империясе җирләрен өч улына – Җучига, Тулуйга һәм Угедейга бүлеп биргәннән соң, Җучи Олысы – Алтын Урда дип атала башлый. Җучи хан үз дәүләтен Болгар иле үрнәгендә төзи, чөнки Идел Болгарстанын яулаганнан соң, монголларны мондагы күп нәрсә таң калдыра: мәдәният һәм мәгърифәт үсеше, илдәге тәртип һәм тормыш матурлыгы, оборона ныгытмалары төзелеше, хәрби көчләр, сугыш стратегиясе, ил сакчылары күрсәткән батырлык һ.б.

Тора-бара Җучи Олысы җирләрендә яшәгән халыкларның тормышы кискен үсеш ала. Киләчәктә үзенә бирелгән «Алтын Урда» исеме – аның хакыйкый бөеклеген, уңышлы һәм чәчәк атучы ил икәнлеген аңлата.

Европада инквизиция көчәйгән, фәннәр үсешенә юллар ябылган һәм тормышны караңгылык баскан чорда Алтын Урдага төрле яклардан галимнәр, һөнәрчеләр килеп туплана. Төрки халыкларны берләштергән бу татар дәүләте торган саен үсә, көчәя бара. Монда татар мәдәнияте, идеологиясе һәм халыкның милли үзаңы оеша. Ул торган саен ныгый, камилләшә бара.

Алтын Урда дәүләтен төрле җирдә төрлечә атыйлар:

– гарәпләр – Дешт-Кыпчак иле, Җучи олысы, яки Төньяк Татар патшалыгы;

– Европада – Кыпчак дәүләте, Татар иле;

– татарлар үзләре – Олуг Олыс, Алтын Урда.

Җучи үлгәч, аның урынына тәхеткә улы Бату утыра. Ул илнең башкаласын Болгар шәһәрендә урнаштыра. Ләкин тиздән аны Идел елгасының түбән агымына күчерә. Аны шундагы җылы климат, йомшак, коры һава торышы һәм иксез-чиксез дала киңлекләре үзләренә тарта. Моннан Җучи Олысының көньягын да, Европа өлешен дә контрольдә тоту җиңелрәк һәм Урта Азия, Кавказ, Иран кебек сәүдә үзәкләре дә якынрак була.

Идарә итү системасы

Илнең төрле регионнары белән идарә итү өчен Батый хан атлы почта курьерлары системасын оештыра. Бу әле моңа кадәр беркайда да күрелмәгән яңалык була. Тора-бара барлык зур юлларда ямнар – почта станцияләре челтәре оеша. Сәүдә юллары аерым өлешләргә бүленә һәм алар белән губернаторлар (даругалар) идарә итә. Алар узган-барган кешеләрне һәм товарларны исәпкә алып, барын да контрольдә тоткан. Монда тулы тәртип булдыру өчен аларның үзләренә чикләнмәгән мөмкинлекләр һәм үз гаскәрләрен дә тотарга рөхсәт бирелгән. Ныклы тәртип урнаштыргач, бөтен империядә урлаулар туктатылган. Нәтиҗәдә товарлар агымы арткан һәм казнага акча кереме күбәйгән. Ямнар – алар хәзерге почта станцияләре, телеграф, тимер юл кебек элемтә вазыйфаларын да үтәгән.

1313 елда ислам Алтын Урдада дәүләт идеологиясенә әверелгәч, башка дини конфессия вәкилләренә дә үз диннәрен тоту өчен тулы ирек һәм руханиларны рәнҗеткән кешеләргә каты җәза бирелгән. Дин башлыклары барлык салымнардан да азат ителгән.

Алтын Урда иленә Көньяк Европаның 3/4 өлеш җирләре һәм Көнбатыш Азиянең 1/2 өлеше кергән. Урта гасырларда ул шәһәр һәм дала халыкларының күчмә культураларын да берләштергән, көчле һәм бай тарихлы уникаль дәүләткә әверелгән.

Монда вәзир дәүләт башлыгы була. Ул хан идарәсе каршындагы диванны (советны) җитәкли. Хан нәселеннән булган хәрби кешеләрнең балалары – угланнар, башкаларныкы – морзалар, ханга буйсынган җирләрнең башлыклары – әмирләр дип аталганнар һәм үз җирләре белән идарә итү өчен аларга махсус ярлыклар бирелгән.

Хан гаскәрләре унлыкларга, йөзлекләргә, меңлекләргә һәм ун меңлекләргә бүленгән. Монда каты тәртип хөкем сөргән һәм һәркемгә үзенең гаскәри бүлеге өчен тулы җаваплылык йөкләнгән. Мәсәлән, бер кешенең куркаклыгы өчен бу хәрби бүлекчәдәге барлык сугышчылар да җавапка тартылган.

Асылда, Алтын Урда – ул барлык төрки халыкларның борынгыдан биләп килгән җирләрен берләштергән зур ил, империя булган. Мәсәлән, анда Идел-Урал регионы, Урта Азия, Казахстан, Себер, Кырым һәм Дәште-Кыпчак җирләре кергән. Димәк, ул шушы җирләрдә яшәгән төрки халыкларны бергә берләштергән көчле дәүләт булган. Шул халыкларның телләре бер-берсенә якын һәм аңлаешлы булганга, яңартылган, баетылган татар теле – ул бөтен Евразия киңлекләрендә яшәгән барлык халыклар өчен уртак телгә, яисә халыкара телгә әверелгән.

Болгар олысы – Алтын Урданың мәдәни үзәгенә әйләнә һәм шәһәрләр төзү буенча Алтын Урдада гына түгел, ул бөтен Евразия киңлекләрендәге дәүләтләр өчен дә матур үрнәк булып тора. Мондагы күчмә шәһәрләр үзләренең мәчетләре һәм базарлары белән бөтен дөнья халыкларын таң калдырырлык, уникаль күренеш була.

Шулай да, шәһәрләрендә бай тормыш кайнаган, югары культуралы бу илнең гомере чагыштырмача кыска була. Үз эчендәге каршылыклар, һава шартлары кискен үзгәрү, килеп чыккан эпидемияләр, табигать катаклизмнары аркасында Алтын Урда дәүләте көчсезләнә, хәлсезләнә бара. Нәтиҗәдә андагы төрле халыклар тулы бәйсезлеккә омтыла башлый. Ни кызганыч, шулай итеп, Евразия киңлекләрендә барлык төркиләрнең бер бөтен булып берләшү процессы туктала һәм күмәк төрки-татар этносы оеша алмый кала.

Алтын Урданың тарихи әһәмияте

Алтын Урда цивилизациясе – ул төрки халыкларның гына түгел, русларның һәм башка халыкларның да уртак ватанына әверелә. Монда үзара ызгышып, бер-берсен талап яшәгән рус кенәзлекләре берләшә һәм көчле дәүләт булып оеша. Сарайда беренче рус патриархаты оеша (Саровский) һәм күп чиркәүләр, монастырьлар төзелә.

Рус дәүләте Алтын Урда канаты астында ныгый, көчәя һәм үсеш ала. Алтын Урда гаскәрләре ярдәме белән шведларны җиңәләр һәм Литва кенәзлегенең яулап алу һәм католикларга әйләндерү сәясәтенә бирешмичә, православие динен саклап калалар. Ниһаять, тора-бара Россия империя булу дәрәҗәсенә ирешә. Ни кызганыч, тик үз тарихларын язганда, руслар Алтын Урда чорын бары тик кара төсләргә генә буйый һәм үз илләре империянең басымы астында, изелеп яшәгән дип раслап килә.

Асылда Алтын Урда белән Рус дәүләте мөнәсәбәтләре вассаллык, яисә үзидарә (самоуправление) рәвешендә төзелә. Монда аларның дәүләт төзелеше, аның идарә системасы һәм мөстәкыйльлеге саклана. Шулай ук тәхеткә утыру тәртибе, милли культура, мәгърифәт, дин, кораллы көчләр, дәүләт төзелеше, сәүдә системасы – барысы да мөстәкыйльлеккә нигезләнгән була.

Александр Невскийның Алтын Урда гаскәрләре белән ныклы хәрби-сәяси союзда булуы да билгеле хәл. Рус кенәзләренә болгар-татар кызларына өйләнү – ул зур дәрәҗә саналган. Мәсәлән, Александр

алтын тарихы

Невскийның әбисе дә, әнисе дә татарлар булган. Алдынгы фикерле сәясәтчеләр: «Татарлар һәм руслар алар бер анадан туган, Алтын Урда балалары кебек. Аларны капма-каршы куярга түгел, киресенчә, Россиянең киләчәге ныклы булсын өчен, үзләрен берләштереп, аралары ныгытырга кирәк. Ләкин дә бу халыкларны бергә кушарга диген сүз түгел!» – дип сөйли.

Европа һәм Азия киңлекләрендә дошманлашып яшәгән халыкларны берләштереп, ике гасыр дәвамында алар тормышын үсеш юлына бастырган Алтын Урда дәүләтенең чынбарлык тарихы белән кызыксыну хәзер торган саен көчәя бара.

Алтын Урда империясенең таркалу сәбәбе

Үзбәк хан ул Алтын Урданың ил башлыклары арасында иң көчлеләрнең берсе була. Урта гасырларда инквизиция котырынып Европа илләрен караңгылыкка батырганда Алтын Урда империясендәге төрле фәннәр, мәгърифәт, һөнәрчелек һәм сәнәгать үсеше моңа кадәр күрелмәгән биеклеккә күтәрелә.

Үзбәк хан тәхеттә утырган чорда Алтын Урда дөньядагы иң көчле һәм бай дәүләтләрнең берсенә әверелә. Ни кызганыч, тик ул үткәргән кайбер реформалар нәтиҗәсендә бу империя торган саен көчсезләнә бара һәм ахыр чиктә бөтенләй таркала башлый. Ә мөндый гайрәтле илнең таркалуына ниләр сәбәпче булган соң?

Беренчедән, Үзбәк хан төркиләрдә меңнәрчә еллар буена сакланып килгән һәм халык демократиясенең нигезе булган корылтайны – үзидарә (самоуправление) системасын юк итә. Бу аның хаталарының иң зурысы була. Чөнки ул дәүләт Конституциясе булган «Яса»дан читләшә. Мәсәлән, элгәре ханнарны бөтен халык Корылтайда сайлагач, аны ак киезгә утыртканнар һәм кулларында күтәреп, җыелган халыкка күрсәтеп чыкканнар. Тора-бара бу тәртип үзгәргән һәм хан үлгәч, аның урынына бер улы утыра башлаган. Ханның уллары күп булу сәбәпле, алар арасында канлы сугышлар башланган. Тәхет яулап, алар бер-берсен үтергәннәр. Чөнки хан улларның һәркайсысы тәхеткә утыру хокукына ия булган.

Нәтиҗәдә 1359-1380 елларда гына да Алтын Урдада 17 хан алышынгач, ил хәлсезләнгән һәм ул таркалу юлына баскан. Даими үзара сугышлар барган җирләрдә тәртип какшагач, чит илләрдән сәүдәгәрләр дә монда йөрми башлаган. Индия, Иран һәм Кытай белән тоташтырган сәүдә юллары Европа-Азия җирләре аша түгел, ә океаннар буйлап, Африканы әйләнеп уза башлаган. Ямнар, базарлар, таможнялар ябылгач, гөрләп торган шәһәрләр хәлсезләнеп, мескен хәлгә калган. Ил бөлгенлеккә төшә башлагач, аның белән идарә итү дә авырайган. Кырым, Хорезм, Руслар иле һәм Идел Болгариясе кебек дәүләтләр бәйсезлеккә юл тоткан.

Икенчедән, «Яса» законнарыннан читләшкәч, җир биләү хокукы да үзгәргән. Элгәре бөтен җирләр дә хан кулында булып, ул аны бирә һәм яңадан да ала алган. Ә Үзбәк ханнан соң бөтен җирләр шәхси биләмәләргә әверелгән һәм алар нәселдән-нәселгә бирелә башлаган. Бу хәл шулай ук ханнарның идарә итү системасының көчсезләнүенә китергән.

Өченче сәбәп – ул борынгы Тәңре дине кагыйдәләренең һәм «Яса» законнарының кинәт Шәригать кануннары белән алышынуы. Мәсәлән, ислам динендәге төп шарт – ул өйләнешүчеләрнең икесе дә мөселман булырга тиеш була. Ә төрки булуы шарт булмаган. Кемдер башка диндә була икән – ул бары тик мөселманлыкны кабул итәргә тиеш булган. Әлбәттә, бу каннар катнашуына китергән һәм җиңелмәс дип саналган төркиләр генотибының да бөтенләе какшаган.

Һәрбер халыкка Аллаһ Тәгалә тарафыннан аның үзенә генә хас булган көч-гайрәт (энергетика) бирелә. Аларның кайберсендәге милли сыйфатлар көчлерәк, икенчеләрендә – түбәнрәк. Халыктагы гайрәтлелек ул аның холкында, темпераментында һәм менталитетында ачык күренә. Бу аның канында туплана һәм нәселдән-нәселгә бирелә. Каннар катнашу нәтиҗәсендә төркиләр канында меңнәрчә еллар дәвамында тупланган һәм сакланып килгән пассионарлыгы (гайрәте, яшәү көче) һәм милли рухы кими, саега.

Дүртенче сәбәп – ул Алтын Урда чорында шәһәрләрнең күбәюе һәм аларның кискен үсеш алулары. Нәтиҗәдә зур урманнар киселеп юкка чыга. Экосистема бөтенлеге бозыла. Климат үзгәрә. Далалар ком чүленә әверелә. Кыш көннәрендә кар юк кими. Шул ук вакытта Каспий диңгезенең суы күтәрелә һәм күп җирләр су астында кала. Килеп торган төрле бәлаләр аркасында халык ашкынып шәһәрләргә туплана. Бу хәл эпидемияләр килеп чыгуына сәбәпче була. Чума чире халыкның дүрттән берен, кайбер җирләрдә туксан процентына кадәр кырып сала.

Ундүртенче гасыр ахырында ил күләмендә зур мәйданнардагы җирләр бушап кала. Бу хәл унҗиденче гасыр башына кадәр дәвам итә. Хәлсезләнгән илдә тәртип урнаштырырга тырышкан Туктамыш ханның планнары да файда бирми. Аның зыялы катлау кешеләрен əзәрлекләве дә зур зыян китерә. Нәтиҗәдә алар хан властена каршы көрәш башлый.

Ә Туктамышның Аксак Тимер белән 1391 һәм 1395 елларда алып барган сугышлары хәлсезләнгән Алтын Урда дәүләтен һәлакәткә китерә. Нәтиҗәдә Урта Идел җирләре тулысынча бушап кала. Ә унбишенче гасыр башында Алтын Урда тулысынча таркала. Ләкин Алтын Урда таркалгач, аның халкы башкалар арасында сеңеп юкка чыккан дип уйларга ярамый. Аның урынында үзеннән аерылып чыккан башка дәүләтләр барлыкка килә:

Көнчыгыш Европаның көньягында – Кырым ханлыгы;

Урал Артында – Себер ханлыгы;

Түбән Иделдә – Әстерхан ханлыгы;

Идел белән Җаек елгалары арасында – Нугай Урдасы;

Идел белән Кама елгалары тирәсендә – Казан ханлыгы;

Урта Иделдә – Рус дәүләте.

Барлыкка килгән дәүләтләр арасында Рус дәүләте иң тормышчан булып чыга. Ул Алтын Урдадан аерылып чыккан илләрдәге иң уңышлы хезмәткәрләрне, галимнәрне һәм төрле халыкларның зыялы катлам кешеләрен үзенә тартып китерә. Нәтиҗәдә ул үсеш юлында булып, иң көчле дәүләтләрнең берсенә әверелә. Русия дәүләте тора-бара Алтын Урдадан чыккан барлык дәүләтләрне басып ала һәм элгәреге бөтен империя җирләренә хуҗа була.

Алтын Урда – Чыңгызхан империясенең эзле бер тармагы

Европаның, Урта Азиянең һәм Төньяк Африка континентларында яшәгән халыкларның күбесенә цивилизация үрнәкләре күрсәткән Алтын Урда иленең язмышын Чыңгызхан империясе тарихыннан башка күз алдына китерү ул һич тә мөмкин түгел.

Кызганычка, тарихчылар арасында Чыңгызханга карата әлегәчә төрле караш яшәп килә. Берәүләр аны дөнья тарихын кискен рәвештә борып, аңа уңай юнәлеш биргән данлыклы полководец һәм төрки халыкларны берләштереп, Евразия цивилизациясенә нигез салган бөек юлбашчы дип исәпли. Икенчеләр – киресенчә, аны ярты Җир шарын басып алып, күп халыкларны җәберләп изгән, кансыз шәхес булган дип раслый. Чынында кем булган соң ул, кешелексез тиранмы, әллә бөтен кешелек тарихын уңай эзгә салган прогрессив реформатормы? Ни булса да, әле хәзерге көндә дә, күпләр аны көчле идеология һәм пропаганда коралы итеп куллана. Берәүләр аңа һәйкәлләр куя, ә икенчеләр аңардан куркыныч карачкы ясый. Ләкин дөреслекне таптап күмеп тә, яндырып та юк итеп булмый. Тора-бара ул җир асларыннан, су төпләреннән калкып чыга, хәтта көл хәлендә дә телгә килеп, күпне сөйли ала.

Мәсәлән, Чыңгызханның хәрби походлары алдыннан аның дипломатлары үзләренең барасы җирләрендә яшәгән халыкларның җитәкчеләрен, аксакалларын хан ирегенә буйсынырга үгетләп, империя канаты астына керү турында сөйләшүләр алып барган. Буйсынган халыкларга алар тимәгән һәм беркайчан да коралсыз халыкка корал күтәрмәгән.

Кем соң ул, бөек Чыңгызхан һәм нинди тормыш юлы үткән? Моны белү өчен ул яшәгән чорларны һәм сәяси хәлләрне күз алдына китерә белергә кирәк: Чыңгызхан яшәгән чорда, яисә уникенче гасыр башында дала халыклары арасында бер-берсе белән талашып яшәгән күпсанлы хәрби дружиналарның барлыкка килүе ул феодализм үсешенә бәйләнгән. Аларның үзара булган каршылыклары да көтүлек җирләре бүлешеп, бер-берсеннән салым түләтергә тырышудан килеп чыккан.

Бу очракта далада ныклы тәртип урнаштыру кирәклеге көн тәртибенә баса. Коралланган хәрби дружиналар арасында Тимучжин (Тимерҗан) иң гайрәтлеләрдән була һәм 1189 елда ул халык тарафыннан хан итеп сайлана. Ә 1206 елда ул бөтен монголларның һәм төрки халыкларның ил башлыгы (Верховный правитель) итеп сайлана һәм «Чыңгызхан» – ханнар ханы дип атала башлый һәм кыска вакыт эчендә үз дәүләтендә катгый тәртип урнаштыра. Аңа буйсынган феодаллар арасында булган каршылыклар да туктала.

Чыңгызхан кыска вакыт эчендә иң көчлеләрдән саналган армия төзи һәм якын-тирәдә яшәгән Себер халыкларын, Төньяк Кытайны, Урта Азиядәге илләрне яулап, дөньяда иң көчле саналган һәм Тын Океаннан Кара диңгезгә кадәр җәелгән җирләрдә империя төзи. Чыңгызхан төзегән «Яса» Конституциясе һәм дәүләт төзү тәртибе барлык төрки дәүләтләр өчен унтугызынчы гасырга кадәр үрнәк һәм өлге булып килә. Хәтта Рус дәүләтенең «Русская правда» дигән 1497 елгы Иван 111 чорындагы иң беренче суд кануннары һәм Явыз Иванның 1550 елдагы судебнигы да «Яса»га һәм христиан дине кануннарына нигезләнә.

«Яса» кануннары аңа кадәр кешелек дәверендә кулланылган күп империяләрнең хокук кануннарын да кулланып язылган. Чыңгызхан иң элек үзе шуңа буйсынган һәм халкыннан да шуны таләп иткән. «Яса» кануннарының әһәмияте бөтен дөнья күләмендә киң таныльган һәм төрле илләрдә аны үзләренчә уңышлы кулланалар.

Фәрит ШИРИЯЗДАНОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

15 июль (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 27 нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 1.50 сәгатьтә калка, 20.23 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 17.00 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Солы сихәте

1 стакан солыны 6-8 тапкыр юалар, 2 стакан суда яртылаш кимегәнче кайнаталар, аннары 2 аш кашыгы бал өстәп, тагын берничә минут пешерәләр. Ашказаны авыртканда, шуны 2-3 өлешкә бүлеп, көн буена эчеп бетерәләр (ашар алдыннан). Диабет белән чирләгәндә, 1 стакан солыны 1 литр кайнар суга салып, дүрт тапкыр кимегәнче кайнаталар, көнечә 3-4 тапкыр, ашар алдыннан, яртышар стакан эчәләр. Яки солыны җебетеп, җылы урынга куялар. Ике тәүлектән ул үрә башлый. Шуны юып, әйбәтләп киптерәләр, тарттыралар. Барлыкка килгән онны аз гына салкын суга салып болгаталар, өстенә кайнар су агызып, 1-2 минут кайнаталар. Кесәлне ясагач ук эчәләр: көненә 1-2 тапкыр берәр стакан.

16 июль (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 2.49 сәгатьтә калка, 21.14 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.58 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Кан басымын төшерү

1 килограмм солыны юып, ярты сәгатькә 2 литр суга салып куялар, аннары сүрән утта 2 сәгать пешереп, сөзәләр, суыткычта саклыйлар. Кан басымы күтәрелгәндә, ярты стакан солы төнәтмәсенә шулкадәр үк сөт кушып, көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала эчәләр.

17 июль (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 29 нчы көне. 29 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кысла йолдызлыгында, 2.48 сәгатьтә калка, 21.47 сәгатьтә бата. 21 сәгать 32 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 16.56 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый.

Бавыр циррозыннан дәва

Ярты килограмм солыны 5 литр суга салып, 1 литрга калганчы кайнаталар, сөзәләр, 500 грамм бал, 50 грамм атланмай өстәп, тагын 10-15 минут пешерәләр, суыткычта саклыйлар. Хроник гепатит һәм бавыр циррозы белән чирләгәндә, көненә 3 тапкыр, ашарга 1 сәгать кала, 1әр аш кашыгы кабалар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

18 июль (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 30 нчы көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 4.00 сәгатьтә калка, 22.09 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.53 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

19 июль (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 5.18 сәгатьтә калка, 22.22 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.48 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Бөер авыртканда

Бөер һәм бәвел куыгы авыруларыннан интеккәндә, 1 стакан солыны 1 литр суда яртылаш кимегәнче пешерәләр, сөзеп, 2 стакан җылы сөт кушалар һәм тагын 20 минут кайнаталар. Көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1/3 стакан эчәләр.

20 июль (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 6.37 сәгатьтә калка, 22.31 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.47 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди әлемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау тәләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Тәмәкене ташлап була

Литр ярымлы кәстрүлнең яртысына солы салып, тулганчы су өстиләр, кайнатып чыгарып, уртача утта ярты сәгать пешерәләр, сөзәләр, 1-2 аш кашыгы тырнак гөл чәчәге салып, яхшылап төреп, җылы урында 7-8 сәгать төнәтәләр, кабат сөзәләр. Ике атна буе көненә 2 шәр стакан төнәтмәне җылы килеш эчәләр.

21 июль (җомга). ***Мөхәррәм аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 7.54 сәгатьтә калка, 22.37 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.43 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Сарымсаклы кыяр

4 кг кыяр, 1 стакан үсемлек мае, дүрттән өч стакан шикәр, 1 чәй кашыгы төелгән кара борыч, 1-2 баш сарымсак, 3 аш кашыгы тоз, 1 стакан 9 процентлы серкә кирәк. Кыярны һәм сарымсакны түгәрәкләп турап, барлык ингредиентларны өстиләр, яхшылап болгатып, 2 сәгать тоталар. Аннары 700 граммлы банкаларга тутырып, 15 минут стерильләштерәләр дә, калай капкач белән ябалар.

Имам нәсыйхәте

Балалар уен мәйданчыгына барсак та, мәктәптән кайтучы укучыларны очратсак та, берәр спорт ярышына барып, үсмерләрнең үзара сөйләшкәнен ишетсәк тә, колаклар үрә тора.

Нигә сүгенә?

Күпчелек балаларның авызыннан ычкынган һәр унынчы гыйбарә – сүгенү сүзе. Барлык балалар да андый түгел, әлбәттә. Әмма бу начар гадәткә ияручеләре байтак. Бәлки, зур булып күренәсе килү теләге, йә шул юл белән үзләрен күрсәтәсе килергә омтылудыр. Ничек кенә акларга тырышсак та, бу чиктән тыш ямьсез гадәтсезлек безнең мөселман балаларын бер дә бизәми шул.

Дөрес, өйдә балаларыбыз авызыннан андый сүзләр ишетелми. Әмма урамга, үз ишләре янына чыккач, алар үзгәрә. Без, өлкәннәр, үз балаларыбызга шул хакта ныклап аңлатсак иде. «Сүгенү сине зур итеп тә, батыр итеп тә, «тека» итеп тә күрсәтми, киресенчә, дәрәҗәңне генә төшерә», – дип, гел тукып торырга кирәк. Тамчы да бит тама-тама каты таштә үз эзен калдыра, шуның шикелле, яхшылыкка чакырып әйтелгән сүз дә йомшак калебкә тәэсир итмичә калмас.

Кем гаепле?

Ә балаларыбыз сүгенергә кемнән өйрәнә соң? Кемдер интернетны, телевизорны, дусларын гаепләр. Әйе, аларда да гаеп бардыр, әмма проблеманың асылы бездә – зурларда. Бала, иң беренче, өйдә, әти-әнисеннән ишетә мондый начар сүзләрне, аннан урамдагы дусларына кабатлый һәм, шул рәвешле, сүгенү сүзләре тарала. Шуңа да, балаларыбызны гаепли башлаганчы, иң әүвәл, үзебез дөрес һәм матур итеп сөйләшергә өйрәник. Үзебез үзгәрми, тәэлими торып, балаларны төзәтә башлау файда бирмәс.

Әгәр дә хәдисләргә күз салсак, сүгенүнең бик начар, бозык гамәлләрдән саналганын күрербез. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Тыйнаклык (оялчанлык) – иманнан, ә иманлы җәннәттә булачак. Сүгенү – дорфалыктан, ә дорфалык (ягымсызлык, сөйкемсезлек) җәһәннәмгә илтә», – дип әйткән (Тирмизи риваяте).

Әйе, әгәр дә ояла белмәсәк, авыздан нинди генә сүзләр чыкмаячак. Ә менә үзебезне кешеләр белән дорфа тотсак, юаш күренмим әле дип, сүгенү сүзләре кулланасак, бу, ахыр чиктә, гөнаһлы гамәлләр булып тупланып, безне уңышсызлыкка алып барыр.

Үзебез хакында «мин – иман әһеле, Аллаһка ышанам, мин – мөселман», дип әйтәбез икән, димәк, без, беренче чиратта, телебезне фәхеш сүзләрдән сакларга бурычлыбыз, чөнки безгә үрнәк булган җәннәт юлын күрсәткән сөекле Пәйгамбәребез «Мөэмингә әрләү дә, ләгънәт кылу да, әдәпсез сүзләр әйтү дә, сүгенү сүзләре куллану да хас түгел», – дип әйтеп калдырган (Тирмизи риваяте).

Үзебезне мөселман дип саныйбыз икән, мөселман кешесенә хас булган гамәлләрне эшлик, ә мөселман кешесен бер дә бизәмәгән, аның намусын пычрата торган гамәлләрдән ерак булыйк, бигрәк тә тел мәсьәләсендә игътибарлы булырга кирәк. Әгәр дә без начар сүзләр кыстырмыйча сөйләшә алмасак, димәк, бу безнең сүз байлыгыбызның бик аз булуын күрсәтә. Сүз байлыгыбыз аз икән, ул безне белемсез, надан кешегә

санарга нигез тудыра түгелме соң? Белем тупламый торып, бу тормышта ничек уңышка ирешербез соң? «Аллаһка һәм Кыямәт көненә ышанучы кеше яхшы сүзләр белән сөйләшсен яки бер нәрсә дә дәшмәсен!» (Мөслим риваяте).

Сүз байлыгы әле ул күңел көзгесенең чагылышы да. Кешенең күңеле саф, яхшы булган саен, телендә дә хәерле сүзләр генә була. Ә күңел көзгең тутыкмасын өчен, уйларыңның да дөрес, яхшы булуы зарур...

Үсеп җиткәч

Кеше бу дөньяга аяк басып, акны карадан аерырга өйрәнгәч, үз-үзенә төрле сораулар бирә башлый. Ни өчен мин бу якты җиһанга килдем? Яшәвемнең максаты нидән гыйбарәт?

Бала әлеге сорауларны башта әти-әнисенә бирә, аннан – укытучыларына. Үз дуслары белән дә бу темаларга сөйләшә. Төрлесеннән төрле җавап ишетеп, төгәл нәтиҗәгә килә алмагач, башка кешеләрдән аерылмыйча, тормыш агымы уңаена яшәүне өстен күрә башлый.

Бу мөһим сораулар тора-бара онытыла. Чөнки инде башка төрле мәсьәләләр барлыкка килә һәм аларны хәл итәргә кирәк була. Әйтик, урта мәктәпне тәмамлаган үсмергә тормышта нинди һөнәр сайларга? Кем булырга? Укыргамы-юкмы? Кемнәрдер 30 яки 40 яшькә җитеп тә, үзенең сәләтен ачыклый алмый, яраткан эшен табалмый интегә, тегендә-монда бәрелеп-сугылып йөри. Ә кайберәүләр тормышта үз урынын таба, яхшы эшкә урнаша. Яраткан берәр шөгыльне керемле кәсеп итеп, шул өлкәдә уңышка ирешеп, халык арасында танылып китүчеләр дә аз түгел.

Төп максат

Әмма бу дөньяда үз теләгәненә ирешкән кешегә дә һаман нәрсәдер җитми кебек, күңеленә нидер тынгылык бирми. Югыйсә, тормышта бәхетле булу өчен һәр нәрсәсе бар: гаиләсе дә, үз йорты, яраткан эше дә... Тик, барыбер, күңелендә тынычлык юк, калебендә – бушлык. Нәрсәне дөрес эшләми?

Әйе, адәм баласы яхшы машинада йөрергә, зур йортта, рәхәт тормышта яшәргә мөмкин, ләкин әгәр дә бу җир йөзендә яшәвенең төп максатына төшенмәсә, күңеленә һич тә тынычлык таба алмаячак. Бу галәмнәрнең Хуҗасын онытып, фани дөньяда Ул кушканнарны үтәмичә гомер кичереп, җир йөзенә ни өчен килгәнебез турында уйламыйча яшәү дөресме соң? Моңа җавапны Коръәндә табабыз: «Аллаһны онытkan (Аның боерыкларын үтәмәгән), шул сәбәпле Ул да аларга үз-үзләрен оныттырган (хәтта үзләренә нәрсә файдалы, нәрсә зарарлы икәнен белмәс булдылар) кешеләр кебек булмагыз. Әнә шулар (Аллаһның итагатеннән чыккан) – фасикъләр» («Хәшер» сүрәсе, 19 нчы аять).

Ни өчен яшибез? Бу дөньяга нигә килдек? Сораулар күп, ә җавабы кайда соң?! Уйлап карыйк әле, безгә берәр кеше тормышта авыр сынауны җиңеп чыгарга булышса, аңа карата нинди мөгамәләдә булабыз? Әйтик, бер кеше бик нык авырый ди. Ул бер табибка барып карый, файда тапмый; икенчесенең дә дәвасы шифа бирми. Хәле көннән-көн мөшкелләнә. Бер дусты килеп, кайсыдыр бер шәһәрдә тәҗрибәле яхшы табиб барлыгын әйтә, аның янына алып бара. Аллаһның рәхмәте белән, ул табиб бу авыру кешене аякка бастыра. Ул кеше үзен әлеге табиб янына алып барган дустына нинди мөнәсәбәт кылачак инде? Әлбәттә, гомере буе рәхмәтле булачак. Чөнки күңеле аны үзенә ярдәм иткән дустының игелегенә игелек белән җавап кайтарырга этәрә.

Рәхмәтле булыйк

Ә хәзер төп сорауга җавап эзләп карыйк. Көн саен кояшны кем чыгара? Басуларда игеннәрне кем үстерә? Чишмәләрдән эчәр суны кем агыза? Шуларны күрә торган күзләрне, җирдә басып йөри торган аякларны безгә кем биргән? «Аллаһ» диярбез бертавыштан. Әйе, шулай. Ә без Аллаһка даими рәхмәтлеме соң?

Аллаһ биргән сәламәтлек какшап китеп, алдагы мисалдагыча, берәрсе ярдәм кулы сузса, ул кешенең яхшылыгына каршы ничекләр генә итеп яхшылык эшләргә дә белмибез.

Ә сәламәтлек һәм башка нигъмәтләре өчен Аллаһка рәхмәтле булырга, Үзе кушканнарын үтәп яшәргә, Үзенә генә гыйбадәт кылырга омтылабызмы? Бу сорауга җавап булачак, яшәвебезнең төп максатын Раббыбыз Аллаһ Коръәндә «Зарият» сүрәсенең 56 нчы аятендә бәян кыла: «Мин кешеләрне һәм җеннәрне бары тик Миңа гына гыйбадәт кылсыннар өчен барлыкка китердем». Гыйбадәт кылуыбыз исә Раббыбызга рәхмәтебезне белдерүне күрсәтә. Шөкер итүебез исә Аның әмерләрен үтәп, Ул тыйган гөнаһлардан ерак булудан башлана.

Раббыбызга буйсынып, Аңа гына гыйбадәт кылып яшәгәндә, Ул күңелебезгә тынычлык салыр, бар малыбызга канәгать булып һәм рәхәтен күреп, бәрәкәт белән, бәхетле тормышта яшәүләрне насыйп итәр. Ни өчен яшәвебезне аңларга, кая барачагыбызны уйлап, ике дөньяны тигез күреп яшәргә Аллаһ Тәгалә ныклы иман бирсә иде.

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының
Тәберде Чаллысы мәчете мөгаллиме.

Рафаэль Сәхәбиевнең каберенә таш та куелмаган

ТАССРның халык артисты Рафаэль Сәхәбиевнең каберен чүп баскан. Күренекле җырчының туган көне алдыннан – исән булса, 8 июльдә аңа 72 яшь тулган булыр иде – ватсап төркемнәре аша аның чүп баскан кабере фотосы үтте. «Ел саен игътибар итәм – Сәхәбиев каберенә һаман да таш куелмаган. Ә бит танылган артист иде. Кабер ташландык хәлдә. Консерваториягә җиткерәсе иде бу хәбәрне», – дип язылган фото астына.

Күренекле җырчы 2019 елның ноябрендә вафат булган иде. Өч ел ярым вакыт үткән, кабер өстендә җирләгәндә кадап куелган такта әлегәчә тора. «Сахабиев Рафаил Ахат улы 08.07.1951 г. – 29.11.2019 г.» дип язылган калай агач тактага беркетелгән. Калай да шактый тузган.

Әлеге фотоны элеккеге хезмәттәшебез, журналист Гөлшат Ганиева да күргән. «Мирныйдагы татар зиратында ул кабер. Дуслар белән без анда барып йөрибез. Бу юлы баргач, Рафаэль Сәхәбиевнең кабер өстен дә булдыра алган кадәр чистарттым. Әмма андагы үләнне кул белән генә чистартып бетерә торган түгел, чалгы кирәк», – диде ул.

«Рафаэль Сәхәбиев кабере янында гына Роберт Миңнуллин кабере дә тора. Аныкы ялт иткән, таш та куелган, чистартылган да», – ди Гөлшат Ганиева.

Үткән ел Роберт Миңнуллин каберенә таш куелу мәрасименә килүчеләр дә янәшәдәге үлән баскан кабергә игътибар иткән иде.

* * *

Күренекле җырчы һәм педагог Рафаэль Сәхәбиевны соңгы юлга Актерлар йортыннан озатуларын яхшы хәтерлим. Хушлашырга аның сәхнәдәшләре, иҗатташ дуслары, кордашлары һәм тамашачысы – совет чорында яшьләгән уздырган өлкән яшьтәге затлы татар интеллигенциясе җыелган иде.

Озату чарасын Татарстан Мәдәният министрлыгы оештырган. Мәрасимне министр Ирада Әюпова алып барды.

«Рафаэль Сәхәбиев – Советлар Союзы буыныннң соңгы артистларыннан. Үзара җыелып сөйләшкәндә зарлана башласак, ул темаңы шаяру белән җиңеләйтә ала иде. Ул зур масштаблы уникаль шәхес һәм артист иде. Рафаэль Сәхәбиев опера театрында да, драма театрында да уйный алыр иде. Бу хакта Марсель Сәлимҗанов белән дә сөйләшкән булды. Рафаэль Сәхәбиев кебек шәхесләр онытылмый», – дигән иде Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов.

«Рафаэль Сәхәбиев гаҗәеп кеше иде. Талант иде. Кызганыч, бөтен иҗаты язмаларда калмаган. Бик күп талантлы композиторлар үз әсәрләрен беренче башкаруны Рафаэль Сәхәбиевка ышанып тапшыралар иде», – дигән иде Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин.

* * *

Быел ТР Мәдәният министрлыгы, мәдәният учреждениеләре, муниципаль районнарның башкарма комитетлары, иҗат берлекләре белән берлектә, «Хәтер өмәсе» акциясе игълан иткән иде. Казанда Яңа татар бистәсе зиратында һәм Арча зиратында ул өмәләр узган – татар театры артистлары һәм язучыларның кабер өсләрен җыештырган һәм кабер ташларын сөртеп торган фоторәсемнәр интернет киңлекләрендә бар. «Хәтер өмәсе» Мирный зиратына килеп җитә алганмы, анда Министрлыкның бөтен мәдәният учреждениеләре катнашканмы – монысы билгесез.

Редакция әлеге сорау буенча ТР Мәдәният министрлыгына, Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенә һәм Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына мөрәҗәгать итте.

ТЕАТР ҖАВАБЫ

«Туганнарының театрга мөрәҗәгате булмады. Алардан башка без ни дә булса эшли алмыйбыз», – дип җавап бирде театрның матбугат үзәге. Театр «Хәтер өмәсе» акциясе кысаларында зиратларны чистартырга да бара алмаган икән, чөнки ул көнне театрда спектакль булган. Матбугат үзәге шулай дип җавап бирде.

КОНСЕРВАТОРИЯ ҖАВАБЫ

Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе рәсми запрос җибәрүебезне сорады. Без аны җибәрдек. Аларның җавабы соңрак булачак.

МИНИСТРЛЫК ҖАВАБЫ

«Рафаэль Сәхәбиев каберенә таш кую буенча эш бара, ташның проектлары да эшләнә. Улы да борчылып йөри. Әмма андый һәйкәл-ташны гаилә үзе дә, ниндидер бюджет оешмасы гына да куя алмый, чөнки мәшһүр кешеләр өчен кабер ташлары күп очракта чын сәнгать әсәре була, һәм алар кыйммәт тора. Әлегә финанс чыганаклары эзлибез», – диде ТР Мәдәният министрлыгының җаваплы бүлек мөдире Айрат Фәйзрахманов.

Кызганыч, республикада шәхесләребезнең истәлеген мәңгеләштерү максатлары өчен аерым программалар, акча чыганаклары каралмаган. Шунлыктан Мәдәният министрлыгы һәр очрак өчен акча эзли, йә булмаса, Татарстан Республикасы Рәисенә мөрәҗәгать итә. Кайбер очракларда туганнар үзләренең яки мәрхүмнең статусына таянып, финанс чыганаклары табарга мөмкин. Кыскасы, һәр очрак индивидуаль хәл ителә.

Әлбәттә, «Ә гаилә?» дигән сорау туачак. Сораштым. Рафаэль Сәхәбиевның 2 гаиләдә 3 баласы, оныклары бар. Хатыннары һәм балалары исән-сау, диделәр аларны белгән кешеләр. Ике гаилә бер-берсенә ышанып ятадыр, бәлки...

Язучы, артист һәм журналист Алмаз Хәмзинга да шалтыраттым. Чөнки якташлар, дуслар икәнен белә идем. Алмаз абый хәбәрдән югалып калды. «Минем дә барганым юк бит… – диде ул, дәшми торганнан соң. – Гаиләләре дә карамаганмы икәнни? Театр да карамаган инде алайса… Кеше кадере юк заман. Үлгәннәрнең дә, исәннәрнең дә кадере юк», – диде ул.

Рафаэль Сәхәбиев 1951 елның 8 июлендә ТАССРның Түбән Кама районы Шәңгәлче авылында туган. 1976 елда Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. 1976 елдан М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты. 1997 елдан Казан консерваториясенең опера классында эшли.

tatar-inform.ru

Салават Камалетдинов фотосы (архив).

Атнаның сәяси мизгелләре

Башлыкларны ни борчый?

Ванкуверда (Канада) күптән түгел (30 июнь – 4 июль көннәрендә) Европада иминлек вә хезмәттәшлек буенча оешманың (ОБСЕ) парламент ассамблеясе (ПА) үзенең һәр елны уза торган 30 нчы сессиясен үткәргән. «Төбәк куркынычсызлыгын демократик һәм инклюзив (иҗтимагый процессларга җәлеп ителгән) җәмгыятьләрне үстерү юлы белән ныгыту: ОБСЕ ПАнең роле» дигән темага багышлап үткәрелгән һәм Россиядәге сәер вакыйгалар фонында барган бу сессиянең эш нәтиҗәләре буенча кабул ителгән йомгаклау декларациясендә ЧВК «Вагнер»ны – «террорчыл оешма», Россияне исә «террорчылык спонсоры» дип тану хакында да әйтелә. Күрәсең, соңгысына депутатларны ЧВК «Вагнер»ның бөтен дөнья буйлап шикле эшләрдә катнашуы һәм бу оешманың дәүләт хисабыннан финанслануы этәргән. Шунысын да искәртеп үтик, ОБСЕ ПА карарлары тәкъдим рәвешендә генә кабул ителә һәм юридик көчкә ия түгел. Ә «РИА Новости» мәгълүматларына караганда, элегрәк (22 июнь көнне) Европа Шурасы парламент ассамблеясе (ПАСЕ) сессиясендә дә Украина низагының сәяси нәтиҗәләре турында резолюция кабул ителгән. Анда бу илдә кылынган хәрби җинаятьләрне тикшерү өчен халыкара трибунал булдыру, шулай ук Украина тарафыннан тәкъдим ителгән «тынычлык планы» сессиядә тулысынча яклау табуы турындагы пунктлар да кертелгән.

Узган атнада сәяси вакыйгалар күп булды. Төркиянең «Азов» батальоны (Россиядә ул тыелган террорчыл оешма санала) җитәкчеләрен низаг туктаганчы ук Украинага кире бирүе Кремльдә ризасызлык уятты. РФ Президентының матбугат хезмәте башлыгы Д.Песков моны, Төркия тарафыннан да, Украина ягыннан да килешү шартларын бозу буларак бәяләде һәм сәбәбен Украинаның контрһөҗүм барышындагы уңышсызлыклары белән бәйләп аңлатты.

Сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да бер җөмлә белән генә бил-гелә п үтик. Сугыш кырында снаряд һәм бомбалар кытлыгын булдырмауда вакытлы чара буларак, АКШ Украинага касеталы сугыш кораллары бирергә карар кылган. Украинага хәрби ярдәмне сугышчан боралаклар һәм башка төр корал белән күрсәтәчәге турында Чехия дә белдергән. Ә Болгария президенты Киевкә корал белән ярдәм итүдән баш тарткан. Вьетнам исә теләсә нинди шартларда да Россия белән бергә булачагы турында белдергән. Төркия Президенты Р.Эрдоган, Украина лидеры В.Зеленский белән очрашканнан соң, Украина НАТО әгъзасы булырга лаек, дип әйткән, бер үк вакытта ул РФ Президенты В.Путин белән августта очрашырга исәп тотуы турында да белдергән. Украина саклану министрлыгы 2022 елның көзендә Кырым күперен шартлатуда үзенең җаваплылыгын таныган. АКШ Президенты Джо Байден 9-13 июль көннәрендә узачак Европага сәфәре барышында Бөекбританиядә булырга, Литвада НАТО саммитында катнашырга (11-12 июль) һәм 13 июльдә Финляндиядә Төньяк Европа илләре саммитында да чыгыш ясарга җыена.

Фоат УРАЗАЙ.

Сабыйларга – сыйфатлы сөт

Натан Штраус – Америка тарихында иң атаклы шәхесләрдән берсе. Кибетләр челтәре хуҗасы һәм үз вакытының иң уңышлы эшкуарларыннан берсе булып, ул үзенең бөтен шәхси капиталын диярлек Нью-Йорк хәерчеләренә тотып бетергән. Натан – сөтне пастеризацияләүне гамәлгә кертеп, йөз меңләгән сабыйга тормыш бүләк иткән кеше. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында АКШ та балалар бик күпләп үлгән, шул исәптән йогышланган сөт эчеп тә. Европа буйлап сәяхәт иткәндә, туберкулез белән йогышланган сыер сөтен эчерткәч, Штраусларның яңа туган кызлары үлә. Шул фаҗига эшкуарны яңа эшчәнлек – сөтне пастеризацияләү (сөтне 60 минут буе 60 градуска яки 30 минут буе 70-80 градуска кадәр җылыту һәм тиз арада суыту процессы) белән шөгыльләнүгә этәрә. Ул чакта пастеризацияләүне сәламәтлек өчен зарарлы, бушка акча түгү дип санаганнар, шунлыктан Штрауска аяк чалырга теләүчеләр бик күп булган. Әмма ул үз акчасына АКШ ның 36 шәһәрендә 297 пастеризацияләү станциясе төзеткән. 1891 елда Нью-Йоркта туган балаларның 24 проценты бер яшь тулганчы үлсә, Штраусның пастеризацияләнгән сөтен эчерткән 20111 баланың алтысы гына җан тәслим кылган. Илдә 1891 елда мең баланың 125 есе үлсә, 1925 елда әлеге күрсәткеч 15 кә кадәр кимегән. Кайбер тарихчылар исәпләвенчә, Натан Штраус барлыгы 445800 сабыйның гомерен саклап калган. Алай гына да түгел, 1893 елдагы икътисади кризис вакытында Штраус сөт станцияләрендә иң арзан бәягә күмер сатуны да оештырган, түләргә хәленнән килмәгәннәргә исә бушка биргән. Юмарт эшкуар, бөтен кирәкле җиһазлар куелган бүлмәле йортлар ачып, 64 мең фәкыйрьне шунда урнаштырган, аларны көн саен 5 центка гына иртәнге аш белән туендырган, 1 центлык 50 мең төшке аш әзерләткән. Үз компанияләрендә эшләүчеләрне көненә бер тапкыр бушлай ашаткан. Натан Штраус 1931 елда 82 яшендә дөнья куйган.

("Интересно.cc").

Яшенме? Кояшмы?

Яшен атудан үлүгә караганда кояш сугудан үлеп китү ихтималы күпкә зуррак икән. Яшеннең температурасы +30000 градуска җитәргә мөмкин. Ел саен Америкада гына да яшен уртача 50 кешенең гомерен өзә. Ә менә кояш сугу ел саен 600-700 кешенең башына җитә, бу яшен атып үтергәннән 12-14 тапкырга күбрәк. Тән температурасы күтәрелгәндә, кеше бик каты тирли, организм исә ничек тә суынырга маташа. Моның өчен ул мөмкин кадәр күбрәк канны тирегә таба куа, кызганычка, кан ниндидер резервтан түгел, ә эчке әгъзалардан суырыла. Кандагы кислород кытлыгы әгъзаларның хәлен тагын да начарайта. Озак вакыт эсседә торганда, бөтен организмда ялкынсыну процесслары башлана, тәнгә суыну авырлаша бара. Температура +40 градустан артса, баш миенә кан азрак килә, баш сөяге эчендәге басым күтәрелә, эчке тукымалар зарарлана, бөерләр эшләми башлый һәм кеше бик интегеп үлә.

("The Local").

Аеруча хөрмәткә лаек

1945 елның 24 июнендә Мәскәүдә узган Җиңү парадында этләр дә катнашкан, ә менә Юлбарыс кушаматлы этне Сталинның шинеленә төреп күтәреп барганнар. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында саперларга мина эзләшкән этләр шактый күп булган, әмма Юлбарыс аларның барысыннан да уздырган – 1945 елның беренче биш аенда гына да Европа илләре территорияләрен зарарсызландыру вакытында ул 7468 мина һәм 150 дән артык снаряд тапкан. Тик парад үткәрер алдыннан яраланган. Шунлыктан Сталин аны үзенең шинеленә төреп барырга боерган.

("Лента.ру").

Зәгъфран могҗизасы

Германия галимнәре үткәргән тикшеренү көтелмәгән нәтиҗә ясарга мөмкинлек биргән: гап-гади куркум (икенче төрле аны һинд зәгъфраны дип тә йөртәләр) баш мие күзәнәкләренең торгызылуына булыша икән. Сынау вакытында галимнәр зарарланган нерв тукымаларының кәүсә күзәнәкләрен куркум төнәтмәсенә салып торган. Бу мохиттә күзәнәкләрнең зур активлык күрсәтүе ачыкланган. Һинд зәгъфранында ике биологик актив компонент булып, аларның берсе күзәнәкләрне торгызуда катнаша, икенчесе исә ялкынсынуны киметә һәм канцерогенга каршы үзлеккә ия. Медиклар әлеге нәтиҗә Альцгеймер чиреннән һәм инсульттан дару табарга булышыр, дип өметләнә, әмма куркумны неврология авыруларын дәвалауда куллану турында сөйләргә иртә әле.

("Der Spiegel").

Төз утыр!

Эш өстәле янында бөкрәеп утырырга яратучыларның аркасы арып һәм умырткалыгы кәкрәеп кенә калмый, алар күңел төшенкелегенә бирелә, явызлана да икән. Тагын шунысына да игътибар иткәннәр: кеше бөкрәйгәндә азрак сөйләшә, сүзләрендә тискәре тойгылар күбрәк була. Ә туры, төз утырырга яратучылар, кагыйдә буларак, һәрвакыт оптимист, шат күңелле. Шунысы дәлилләнгән: әгәр кеше бөкрәеп утыра йә йөри икән, бу баш миенә һәм башка әгъзаларга кислород килүне акрынайта, ашкайнатуны боза, гел йокыны китерә. Сулыш алу да кирәгенчә тирән булудан туктый.

("The Times").

Сәер корылмалар

